Самарские татары

# Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ Ж… …ЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 3 (48), ИЮЛЬ–ДЕКАБРЬ 2025

ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА



ЕГО ДВАЖДЫ ПРЕДСТАВЛЯЛИ К «ЗОЛОТОЙ ЗВЕЗДЕ»



## Мидхәт Әминов. *Гармунга мәңгегә гашыйк кеше*



ТАМЫРЛАРЫН САКЛАРГА ТИЕШБЕЗ



ТАТАРЛАР – ТАРИХТА ТИРӘН ЭЗЛЕ ХАЛЫК



СИМВОЛЫ НОВОГО ГОДА

6+



# 2026НЧЕ ЕЛ МӨҺИМ ВАКЫЙГАЛАРГА БАЙ БУЛАЧАК

## *Газиз милләттәшләр, кадерле дуслар!*

*2025 елга йомгак ясап, ирешкән уңышларыбызга сөенеп, кайбер югалтуларга күңелсезләнеп, 2026 елга максатлар билгеләү вакыты җитте.*

*Махсус хәрби операция чорында илебезнең бәйсезлеге һәм тынычлыгы өчен көрәшкәндә без илкүләм җитәкчебез В.В. Путин һәм ватаныбызны саклаучылар янында бердәм булдык. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап, һәрвакыт ныклык һәм мәрхәмәтлек үрнәге күрсәтергә омтылабыз.*

*Ел буена Самар өлкәсе «Туган тел» татар җәмгыяте милләттәшләребезнең шатлыкларын да, кайгыларын да уртаклашты. Халыкны берләштерүгә юнәлдерелгән чаралар узды, уй-ниятләр тормышка ашты. Милләт киләчәге өчен тырышып хезмәт куйган барлык кешеләргә чиксез рәхмәтләремне җиткерәм.*

*2025 ел вакыйгаларга бай булды. Өлкәбездә нәшер ителә торган «Бердәмлек» татар газетасы үзенең 35 еллыгын, «Ялкынлы яшьлек» җыр, бию һәм шигърият ансамбле 55 еллыгын билгеләп үтте. Өлкә матбугат мәйданы киңәйде, «Россия татарлары» дигән федераль журнал чыгара башладык. Россиядә татар җәмгыяте оешмалары булмаган төбәк юк диярлек. Федераль журнал — башка төбәкләрдәге эшчәнлек тәҗрибәсен, уңышларны һәм практикаларны уртаклашу, төрле җәмгыятьләр арасындагы элемтәләрне ныгыту, җәмгыять алдында торган мәсьәләләрне уртак юллар белән хәл итү мөмкинлеге.*

*2026 елда Камышлы районы торгызылганына 35 ел тулуны билгеләп үтәчәкбез. Бу уңайдан матур, истәлекле чаралар узачагына өметләнәм.*

*Яңа елда да бердәм булып, куйган бурычларыбызны һәм планнарыбызны тормышка ашыруда уңышларга ирешербез, дип ышанам.*

*Бәйрәм белән иң җылы котлауларымны кабул итегез. 2026нче ел мөбарәк, игелекле булсын. Безгә саулык-сәламәтлек, күңел күтәренкелеге, теләктәшлек алып килсен. Барчабызга мул тормыш һәм тыныч көннәр телим.*

**И.Г.ШӘКҮРОВ,**
Самар шәһәренең Иҗтимагый палата әгъзасы, өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте президенты, өлкә татар эшкуарларына ярдәм итү ассоциациясе рәисе, «Самар татарлары», «Россия татарлары» журналларын һәм samtatnews.ru мәгълүмат медиа-порталын оештыручы

# Хөрмәтле дуслар!

Менә вакыйгаларга, ачышларга һәм яңа офыкларга бай булган тагын бер ел ахырына якынлаша. Йомгак ясап, һәрберебез аның үзе, туганнары, якыннары һәм тулаем илебез өчен нинди булганлыгын анализлый.

Без киләчәк турында уйланабыз, планнар төзибез һәм, кыш соңга калса да, Яңа ел алды бәйрәм кәефенең килүен көтәбез.

Узып баручы елда «Самар татарлары» редакциясе коллективы гадәттәге дүрт сан урынына нибары өч сан чыгарды. Бу 2025 елда яңа проект өстендә эшләвебез – “Россия татарлары” журналын бастыра башлавыбызга бәйле. Ике санны чыгарып карадык һәм, мөгаен, киләсе елда көчебезне нәкъ шушы федераль проектны гамәлгә ашыруга юнәлтербез. Һәм бу аңлашыла да, безгә дә үсәргә, алга атларга кирәк. Әлбәттә инде, әлеге журналда Самар татарлары турындагы мәкаләләр шулай ук басылып киләчәк. Тик хәзер безнең турында өлкәбездә генә түгел, әчит төбәкләрдә дә беләчәкләр.

Ә бу санныбызда, һәрвакыттагыча, халкыбызның гореф-гадәтләре байлыгын күрсәтергә, сезне Самарның күренекле татарлары белән таныштырырга, төрле буын вәкилләрен берләштерә һәм милли мәдәниятне саклап калуга ярдәм итә торган вакыйгалар һәм чаралар турында сөйләргә тырыштык.

Редакциябез сезгә игътибарыгыз һәм ярдәмегез өчен рәхмәтен белдерә!

Якынлашып килүче Яңа ел сезгә тынычлык, шатлык, иминлек һәм илһам китерсен!

Авторларыбызга бу басма өстендә эшләгәннәре өчен рәхмәт белдерәбез, һәм ул сезгә, хөрмәтле укучыларыбыз, күңелле мизгелләр һәм яңа белемнәр бүләк итәр дип өметләнәбез.



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналының баш мөхәррире*

РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –**
президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –**
председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович –**
гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –**
главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович**
имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –**
старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –**
председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –**
директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширияздaнов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Дорогие друзья!

Вот и подходит к концу еще один календарный год, насыщенный событиями, открытиями и новыми горизонтами. Подводя его итоги, каждый из нас анализирует, каким он был для него, для наших родных и близких, для страны в целом. Мы задумываемся о будущем, строим планы и, несмотря на запоздалую зиму, ждем наступления праздничного предновогоднего настроения.

В уходящем году коллектив редакции «Самар татарлары» вместо привычных четырех номеров выпустил всего три. Связано это с тем, что 2025 год для нас стал стартом для нового проекта – создания общероссийского журнала «Татары России». Было выпущено два пилотных номера, и, скорее всего, в наступающем году наши силы будут сосредоточены на реализации именно этого федерального проекта. И это мы считаем вполне логичным и объяснимым: мы тоже растем и нам нужно двигаться вперед. При этом смена «прописки» журнала вовсе не означает, что мы не будем писать о самарских татарах. Будем, но теперь о нас будут знать не только в Самарской области, но и далеко за ее пределами.

А в этом номере журнала мы, как всегда, постарались показать богатство традиций и обычаев нашего народа, познакомить вас с выдающимися самарскими татарами, рассказать о событиях и мероприятиях, которые объединяют представителей разных поколений и способствуют сохранению национальной культуры.

Наш коллектив благодарит вас за внимание и поддержку! Пусть наступающий Новый год принесет вам мир, радость, благополучие и вдохновение! Мы благодарим наших авторов за работу над этим выпуском и надеемся, что он подарит вам приятные минуты чтения и новые знания.

# Содержание:

Соңгы 25 ел эчендә иң масштаблы чара ....... 6
Будем держаться вместе ....... 10
Мортазин укулары безгә үз-үзебезне яхшырак белергә ярдәм итәчәк ....... 13
Знатный универсал культурной нивы ....... 15
Его дважды представляли к «Золотой Звезде» ....... 25
Пришлось писать две докторские диссертации ....... 31
Тамырларын сакларга тиешбез ....... 38
25 елдан соң очрашу ....... 41
Булгары против монголов ....... 45
Разбойники, бандиты и неблагородные пираты ....... 47
Туган якка игелекле булу изгелекләр тудыра ....... 49
Татарлар – тарихта тирән эзле халык ....... 51
Мидхәт Әминов. Гармунга мәңгегә гашыйк кеше ....... 60
“Яшьләргә тәүфыйк- һидәят сорыйм” ....... 66
Ислам диненә килергә беркайчан да соң түгел ....... 68
Татар җәмгыяте юлын яктыртучы маяк ....... 84
“Хәтта уй-фикерләребез дә тәңгәл килгән безнең!” ....... 85
Жизнестойкость народа зависит от лидеров, способных заботиться о его судьбе ....... 89
Символ Нового года ....... 93
В краю полей и берез ....... 104



74 КАНАФИЕВЫ. ИХ РОДИНА – ТЕПЛЫЙ СТАН



70 СПОРТ – УДЕЛ СМЕЛЫХ И СИЛЬНЫХ



55 МАКСАТЫНА ИРЕШКӘН БӘХЕТЛЕ АНА



96 СЕВЕРНАЯ КОРЕЯ

## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2024 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**

Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 3 (48), июль–декабрь, 2025
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 29 декабря 2025 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная

# ГЛАВА КАМЫШЛИНСКОГО РАЙОНА УШЕЛ В ОТСТАВКУ

*«Камышлинские известия»*



28 ноября состоялось расширенное заседание Собрания представителей муниципального района Камышлинский, на котором были приняты ключевые решения, касающиеся руководства и управления районом. Районное Собрание официально приняло отставку главы района Рафаэля Багаутдинова, поданную по собственному желанию.

Глава района подал в отставку по собственному желанию, направив соответствующее заявление в представительный орган муниципального образования. На расширенном заседании депутаты единогласно поддержали решение об отставке. Это стало первым пунктом повестки заседания.

Процедура отставки регулируется уставом муниципального образования и Федеральным законом № 33-ФЗ. На расширенном заседании Собрания экс-глава произнес прощальную речь. Говорил сдержанно, но в глазах стояли скупые мужские слезы. Он поблагодарил команду за годы совместной работы, выразил признательность коллегам и жителям района, отметив ключевые достижения, и подчеркнул, что район заметно преобразился благодаря общим усилиям. В завершение он пожелал району дальнейшего развития и выразил уверенность в том, что преемник продолжит начатые проекты.

Теплыми речами выступили главы соседних районов. Каждый из них отметил профессионализм, выдержку и человечность Рафаэля Камиловича Багаутдинова. Многие вспомнили сложные ситуации, в которых он находил верные решения, и подчеркнули, что его уход – большая потеря для района. Жители района также присоединились к словам благодарности и выразили свои теплые пожелания. В адрес экс-главы прозвучали пожелания крепкого здоровья, семейного благополучия и новых профессиональных свершений. Некоторые вспоминали конкретные добрые дела и проекты, реализованные при его участии – от ремонта дорог, до благоустройства территорий. Также депутаты утвердили на расширенном заседании Собрания представителей проведение открытого конкурса на замещение должности главы муниципального района Камышлинский.



# ВСЕМИРНЫЙ КОНГРЕСС ТАТАР ОБЪЯВИЛ 2026 ГОД ГОДОМ ГАБДУЛЛЫ ТУКАЯ

*Milliardtatar.ru*

Инициатива, предложенная председателем совета «Милли Шура» Василем Шайхразиевым, была единогласно поддержана всеми членами совета. Решение приурочено к 140-летию со дня рождения поэта.

Василь Шайхразиев сообщил, что предложение также поддержал Раис Татарстана Рустам Минниханов. В рамках тематического года запланированы различные мероприятия, посвященные не только Тукаю, но и другим юбилярам.

# НОВЫЙ ТЕАТР КАМАЛА В КАЗАНИ СТАЛ ПОБЕДИТЕЛЕМ ПРЕМИИ «ЗОЛОТОЙ ТРЕЗИНИ – 2025»

*kommersant.ru*

Новый театр Камала в Казани стал победителем 8-й Международной премии «Золотой Трезини – 2025» в номинации «Лучший реализованный проект общественного здания или сооружения», сообщается на сайте награды.

Авторы премии подчеркнули, что новый театр Камала не только выполняет свою основную функцию, но и служит многофункциональным культурным центром Казани.



Театр Камала – старейший национальный театр России, основанный в 1906 году. Первый спектакль на татарском языке был сыгран в том же году. В 1986 году на противоположном берегу озера было построено модернистское здание театра, которое для своего времени считалось инновационным и футуристичным. Отмечается, что новое здание продолжает эту традицию, отражая культурный и архитектурный дух современности.

# ТАТАРСТАН ВОЗГЛАВИЛ РЕЙТИНГ ТРУДОУСТРОЙСТВА В РОССИИ

*Milliardtatar.ru*

Республика Татарстан, Забайкальский край и Амурская область возглавили рейтинг трудоустройства, основанный на оценках соискателей. Ключевыми критериями стали не только зарплата, но и общий баланс условий труда.

Топ-3 региона:

- Татарстан (68 баллов): стабильность (безработица – 1,7%), доход 81,1 тыс. руб.
- Забайкальский край (67,6 балла): высокая медианная зарплата 112,8 тыс. руб.
- Амурская область (67,3 балла): рекордно низкая безработица (1,2%), доход 101,8 тыс. руб.

Эксперты отмечают тренд: соискатели все чаще предпочитают высоким, но «стрессовым» доходам в столицах стабильность и возможность карьеры в своем регионе. Москва и Санкт-Петербург в этом рейтинге заняли только 31-е и 23-е места.

## КАРАБИКОЛ ҺӘМ ТАТАР ӘБДЕКИЕ ҮТКӘННӘРЕ ТУРЫНДА КИТАП ЧЫКТЫ

Самар төбәгенең үткәне турында чираттагы китап дөнья күрде. Ул “Ике авыл – бер язмыш. Карабикол һәм Татар Әбдекие тарихы очерклары” дип атала.

Әлеге популяр фәнни басмага язылган аннотациядән күренгәнчә, ул “Самар өлкәсенең Шенталы районында урнашкан ике авыл тарихына багышланган. Аларның язмышында төбәгебез һәм тулаем илебез тарихының мөһим этаплары, XVIII – XXI гасырларда авыл хуҗалыгы һәм Россия крестьянлыгы үсешенең төп тенденцияләре, тикшерелүче чорда илнең сәяси һәм социаль-икътисадый системасындагы үзгәрешләр чагылыш тапкан. Шул ук вакытта ике тугандаш авыл җирлеге тормышының милли-рухи аспектларына да аерым игътибар бирелә.

Китапта шулай ук гомумтарихи характердагы күп кенә мәсьәләләр дә чагылдырылган: Шенталы җиренең археологик үткәне, кешеләрнең яңа заманда төбәккә килеп урнашуы, сугышлар, инкыйлаблар, 1921 – 1922 еллардагы ачлык, халык мәгарифенең совет системасын торгызу, 1920 – 1930 еллардагы мәдәни революция, Бөек Ватан сугышы чорында тыл районы тормышы, авыл хезмәтчәннәренең көнкүреше, инкыйлабка кадәрге һәм совет чорындагы дәүләт-дини мөнәсәбәтләр һәм башкалар.

“Карабикол” җәмгыяте җитәкчесе Ф.Г. Гарифов инициативасы һәм төп матди ярдәме белән бастырылган бу китап гуманитар дисциплиналар өлкәсендәге белгечләр, тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр, мәктәп укытучылары һәм укучылары, тарихи факультет студентлары һәм үз төбәге тарихы белән кызыксынучы һәр кеше өчен кызыклы булачак.







## ПРАЗДНИК КУЛЬТУРЫ И ЕДИНСТВА НАРОДОВ

*tatar-congress.org*

30 ноября в Сиднее состоялось яркое и масштабное празднование татарского национального праздника Сабантуй, который в 2025 году стал настоящим фестивалем дружбы, культурного многообразия и единения народов. Сабантуй в Сиднее стал завершающим Сабантуем года по всему миру и собрал более 500 гостей.

Главным организатором выступила Ассоциация татарского наследия Нового Южного Уэльса Австралии под руководством Лилии Ансафовны Самигуллиной. В подготовке активно участвовал оргкомитет, включающий представителей татарской общины и соотечественников, проживающих в Австралии.

## «МИЛЛИАРД ТАТАР» ОПРЕДЕЛИЛ ЛУЧШИХ




В Казанском Кремле прошла церемония награждения победителей рейтинга «Татары года – 2025». Помимо народного голосования, редакция «Миллиард.Татар» определила 10 победителей, получивших звание «Татарин года» и «Татарка года». Еще двух победителей определили эксперты. Также в этом году впервые были вручены дипломы в номинации «Без булдырабыз». В номинации «Учитель татарского языка / предметник на татарском» победителем стала учитель татарского языка и литературы самарской школы «Яктылык» римма Ильдусовна Хайрова.

## В САМАРСКОЙ ОБЛАСТИ ПОДВЕДЕНЫ ИТОГИ XXVIII ОБЛАСТНОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ АКЦИИ «БЛАГОРОДСТВО»

**Председатель совета местной мусульманской религиозной организации «Самарская историческая мечеть» Усман Владимирович Илингин победил в номинации «Созидатель-меценат».**

В 2025 году в оргкомитет акции «Благородство» поступило более 200 заявок из различных городов и районов губернии. Лауреатами акции стало 69 человек и 4 организации (всего 73 лауреата).

Первая церемония награждения состоялась в Самаре 2 декабря, в Самарской областной универсальной научной библиотеке. В этот день чествовали героев акции, проживающих в Самаре.




Награждение лауреатов из других муниципалитетов будет проходить в течение месяца в различных городах и районах Самарской губернии. В рамках акции «Благородство» пройдут выездные концерты с участием ведущих самарских артистов и творческих коллективов. В торжественной обстановке будут вручены дипломы и подарки.

## В СЫЗРАНИ УВЕКОВЕЧИЛИ ПОДВИГ АЗИЗА КУДРЯКОВА

*islamnews.ru*



В преддверии Дня героев Отечества в Сызрани открыт мемориал Героя Российской Федерации, гвардии старшего лейтенанта Азиза Махсутовича Кудрякова.

Азиз Кудряков родился в Сызрани 3 декабря 1996 года. Окончил школу № 19. После выпуска из Сызранского высшего военного авиационного училища летчиков получил назначение на должность летчика-оператора. С 2022 года – командир вертолета Ми-28. Принимал участие в военной операции в Сирии. Участник специальной военной операции. Выполняя боевые задачи, всегда проявлял мужество и героизм. Каждый его вылет был результативным.

25 июля 2024 года при выполнении боевого задания вертолет Ми-28 под управлением Азиза Кудрякова потерпел крушение. Экипаж погиб.

Указом Президента РФ гвардии старшему лейтенанту Азизу Махсутовичу Кудрякову присвоено звание Героя Российской Федерации (посмертно).



## ЙОСЫФ КЫЗЫ ГАЛИЯ МОСТАФИНА ВАФАТ БУЛДЫ...

Искиткеч моңлы тавышлы Галия ханым, күп еллар буена Самарның “Ялкынлы яшьлек” җыр, бию һәм шигърият ансамбле, “Идел” татар халык эстрадасы ансамбле эшчәнлегендә катнашып, тамашачыларны матурдан-матур җырлары белән шатландырып яшәде. Ә соңгы елларда, дингә килгәч, сәхнәдән үзәккә үтеп керерлек мөнәҗәтләр башкарды. Җирле татар мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертүче кешеләрнең берсе иде ул.

Моңлы сандугачыбыз күзләрен мәңгелеккә йомды. Шәһәребезнең татар җәмгыяте бу зур югалтуны бик авыр кичерде.

Галия Йосыф кызының урыны җәннәт түрләрендә булсын. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

## АЙДАР РАСТЯМОВИЧ ЗАРИПОВ – ВРИО ГЛАВЫ КАМЫШЛИНСКОГО РАЙОНА

*Samtatnews.ru*

Губернатор Самарской области Федорищев В. А. по распоряжению от 2 декабря 2025 г., в связи с досрочным прекращением полномочий главы муниципального района Камышлинский Самарской области Багаутдинова Р. К., назначил временно исполняющим полномочия главы муниципального района Камышлинский Самарской области главу сельского поселения Новое Усманово Зарипова Айдара Растямовича до дня вступления в должность вновь избранного главы муниципального района Камышлинский Самарской области.

Зарипов Айдар Растямович родился 7 декабря 1970 года в селе Новое Усманово Клявлинского района Куйбышевской области. В 1978 году пошел в 1 класс Новоусмановской средней школы. В 1988 году окончил школу с серебряной медалью.

С 1988 по 1989 год обучался в ГПТУ № 66 города Самары на водителя автомобиля.

С 1989 по 1991 год – служба в рядах Вооруженных Сил. С 1991 по 1996 год учился в Самарском государственном техническом университете на нефтяном факультете.

С 1997 года по 2004 год – предприниматель.

В апреле 2004 года назначен главой Новоусмановской волости. В декабре 2005 года избран главой сельского поселения Новое Усманово. С 25.06.2007 по 11.06.2009 работал на должности заместителя Главы муниципального района Камышлинский по строительству, архитектуре и ЖКХ.

С 15.06.2009 – начальник участка по сервисному обслуживанию в «Байтуган Сервис».

В марте 2010 года избран Главой сельского поселения Новое Усманово муниципального района Камышлинский.

Женат, двое детей.



## ТАТАРСТАН УСТАНОВИЛ РЕКОРД ПО ИНВЕСТИЦИЯМ, ПРЕВЫСИВ 1,17 ТРЛН РУБЛЕЙ ЗА ТРИ КВАРТАЛА

*milliard.tataru*

За девять месяцев 2025 года инвестиции в основной капитал Татарстана достигли рекордной суммы – 1,174 трлн рублей. Это почти 1,2 трлн рублей, что на 23,2% превышает показатель аналогичного периода прошлого года, свидетельствуют данные Росстата.

Несмотря на впечатляющий рост в Татарстане, общая динамика по Приволжскому федеральному округу (ПФО) остается сдержанной. Совокупный объём инвестиций в округе увеличился лишь на 0,8%, составив 3,73 трлн рублей.



# СОҢГЫ 25 ЕЛ ЭЧЕНДӘ ИҢ МАСШТАБЛЫ ЧАРА

**5 - 7 ноябрьдә Самарда XIII Халыкара «Россия — спорт мәмләкәте» форумы узды**

***Президент Владимир Путин тарафыннан гамәлгә куелган масштаблы спорт чарасы беренче тапкыр 2009 елда Казанда үткән иде. Шулай ук форум Мәскәүдә, Саранскида, Якутскида, Чебоксарда, Владимир өлкәсендә, Ульяновскида һәм Түбән Новгородта уздырылды. Бу вакыт эчендә ул физик культура, һөнәри һәм массакүләм спорт өлкәсендәге мөһим темалар буенча фикер алышу өчен төп мәйданчыкка әверелде.***

***Венера Галимова***




Самар әлеге чараны уздыруга ел ярым әзерләнде. Шушы дәвердә губернада яңа спорт объекты барлыкка килде, спорт федерацияләре белән берлектә эшләнгән «Мастер-спорт» программасы гамәлгә куелды. Тренерларның абруен күтәрү буенча да зур эш башкарылды. Мәсәлән, алар өчен өстәмә түләүләр кертелде. Ә Самар спортчыларына Россия чемпионатларында һәм округ ярышларында катнашу өчен финанс ярдәм каралды.

Халыкара спорт форумы кысаларында йөзләгән вакыйга үткәрелде: министрлар белән эшлекле дискуссияләрдән алып, массакүләм йөгерүләргә һәм кайнар ярышларга кадәр. Моннан тыш, өлкәбез чарада катнашучылар һәм кунаклар өчен театрларны, концерт залларын, шулай ук Самар һәм Тольяттиның 16 мәдәни объектын үз эченә алган, 5 музей-күргәзмә маршрутын берләштергән киң күләмле мәдәни программа да әзерләгән иде.

5 ноябрьдә «Россия – спорт мәмләкәте» форумын рәсми рәвештә ачу алдыннан Самарда «Чиста спорт» дип аталган масштаблы йөгереш узды. Иртәнге як булуга һәм көзге салкынча һава торышына карамастан, стартка 10 000нән артык кеше чыкты. Ярышларда дөнья һәм Олимпия чемпионнары, сәясәтчеләр, эстрада йолдызлары, махсус операция хәрбиләре катнашты. Финишка килеп җиткән һәр йөгерүчене уникаль коллекцион медаль белән бүләкләделәр. Старт пакетын биргәндә һәр катнашучыга форум символикасы төшерелгән башлык та тапшырылды.

Ә иртәнге сәгать 10да «Солидарность Самара Арена» стадионында чараның күргәзмә экспозициясе ачылды. Халыкара спорт форумына җыелган кунакларны ил президенты Владимир Путин онлайн сәламләде һәм статс-секретарь – Россиянең спорт министры урынбасары Александр Никитин бәйрәмгә рәсми старт бирде.

Чараның эшлекле программасы башланды. Анда Россиянең триатлон федерациясе президен-




ты Ксения Шойгу, Россия Хоккей федерациясенең беренче вице-президенты Роман Ротенберг, синхрон йөзү буенча өч тапкыр Олимпия уеннары чемпионы Мария Киселева, футболчы Андрей Аршавин һәм башкалар катнашты. Биредә корпоратив спорт, җыелма командаларның киләчәге, Россиянең спорт резервын әзерләү, милли спорт төрләре: традицияләрне заманча форматта ничек сакларга, ясалма интеллект, аны спорт индустриясендә куллану һәм башка мөһим темалар турында фикер алыштылар.



Бу вакытта шәһәрнең төрле спорт мәйданчыкларында дроннар узышы буенча Россия Кубогы, «Син - спортта» балалар физкультура-спорт фестивале, Ксения Полякованың «Чемпион канаты астында» нәфис гимнастика, керлинг, боулинг буенча халыкара ярышлар, «Безнең заман геройлары» следж-хоккей Россия чемпионаты узды. Чемпионнар Артем Зотов һәм Анастасия Зверинцева бильярд яратучылар өчен мастер-класслар оештырдылар. Фиджитал-спорт буенча фестиваль-ярышлар үтте.



6 ноябрьдә Высоцкий исемендәге спорт сараенда узган «Киләчәк хакына спорт: бергә җиңәбез» пленар утырышы эшлекле программаның төп вакыйгасы булды. Форумның бу өлешендә президент Владимир Путин да катнашты. Самарга сәфәрен ил башлыгы шәһәрнең “Орбита” спорт комплексын караудан һәм анда шөгыльләнүче яшь буын белән аралашудан башлады. Аннан соң Владимир Владимирович шәһәрнең тарихи үзәгенә ашыкты.

“Быел форумны безнең Идел буеның иң матур, иң үзенчәлекле шәһәрләренең берсе, үзенең казанышлары һәм традицияләре, шул исәптән спорт традицияләре белән дә танылган Самар кабул итә. Исемнәре дөнья спорты елъязмасына кергән күп кенә атлетларыбыз Самар җирендә туганнар”, – дип башлады сүзен президент.

Ил башлыгы Россия, планетаның күпчелек дәүләтләре кебек үк, тигез хокуклылык, бер-берсенең мәнфәгатьләрен саклау, милли мәдәниятләрне хөрмәт итү нигезендә илләр һәм халыкларның үзара хезмәттәшлеген яклаганны билеләп үтте.



– Безнең позиция үзгәрешсез: атлетларның халыкара турнирларга керү мөмкинлеге тигез, аларның спорттагы казанышлары белән нигезләнгән булырга тиеш, ә сәясәткә спортта урын юк. Спорт, мәдәни һәм гуманитар хезмәттәшлек конфликтлар тоткыны булырга тиеш түгел, – дип ассызыклады президент. Ул шулай ук Россия Паралимпия комитетының хокукларын торгызуны гадел карар дип атады.

Пленар сессиядә Сербия Республикасының, Россия Федерациясенең спорт министрлары, Россиянең Олимпия комитеты президенты, Беларусь Республикасының, Казахстан Республикасының туризм һәм спорт министрлары, Зимбабве Республикасының спорт, ял, сәнгать һәм мәдәният эшләре министры, Азиядә хезмәттәшлек буенча Диалог генераль секретаре, Замбия Республикасының Милли олимпия комитеты президенты, Халыкара дзюдо федерациясенең башкарма комитеты әгъзасы, Олимпия спорт төрләре федерацияләренең Африка конференциясе президенты катнашты.

Пленар утырыш кысаларында министрлар һәм спорт ведомстволары башлыклары алга таба спортны үстерүнең төп процесслары һәм халыкара хезмәттәшлек перспективалары турында үз фикерләрен белдерделәр. Балалар-яшүсмерләр спортына һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларны тернәкләндерүгә аерым игътибар бирелде.

Пленар утырыштан соң Владимир Путин Самарда төзелә торган адаптив спорт буенча демонстрацион-агарту үзәгенең презентациясе белән танышты. Объектны дәүләт башлыгы кушуы буенча төзиләр.

Үзәк мәйданчыгында 30дан артык төрле адаптив юнәлеш эшләячәк. Бу сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирәчәк.

Параллель рәвештә спорт ярышлары да дәвам итте. Форумның икенче көнендә опера һәм балет театрында «Бокс төне» узды. «Самара Арена»да - следж-хоккей буенча ярышлар, «Ипподром-Арена» спорт комплексында – сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен йөзү буенча Бөтенроссия «Ватанны саклаучылар кубогы» ачык ярышлары, «Самара Арена» стадионында – «Футбол дәресе» фестивале, шулай ук шәһәрнең төрле спорт мәйданчыкларында шахмат буенча Росконгресс Кубогы, «Үзеңне үзгәрт» фитнес фестивале, ММА буенча халыкара ярышлар һәм Тольятти шәһәренең «Лада-Арена» боз сараенда Алексей Немовның «Спорт легендалары. Мирас» театральләштерелгән тамашасы үтте.

Форумның мөхтәрәм кунаклары арасында Бахрейн Корольлегенең спорт буенча Баш идарәсе директоры Абдулрахман Садик Аскар; Венесуэла Боливариан Республикасының спорт министры Франклин Амилка Кардильо Ромеро; Су спорт төрләре федерациясе президенты Дмитрий Мазепин; Бөтенроссия җиңел атлетика федерациясе рәисе Петр Фрадков; Россия Федерациясенең Халыкара эшләр буенча Федерация Советы Комитеты әгъзасы, грек-рим көрәше буенча өч тапкыр Олимпия уеннары чемпионы Александр Карелин; Совет һәм Россия сәяхәтчесе Федор Конюхов һәм милләттәшебез – танылган блогер, спортчы, альпинист, Уфа шәһәре мэрының уңайлы мохит буенча киңәшчесе Рөстәм Нәбиев та бар иде.

Халыкара «Россия – спорт мәмләкәте» форумы – спорт тармагындагы төп вакыйгаларның берсе, аның барышында физкультура, һөнәри һәм массакүләм спорт өлкәсендәге төп темалар турында фикер алышалар. Бу диалог һәм тәҗрибә уртаклашу мөмкинлек-

ләре мәйданчыгы, үз проектларыны тәкъдим итәргә һәм эшлекле элемтәләрне киңәйтергә ярдәм итүче урын.

Чара Олимпия чемпионнарын, башкарма хакимиятнең тармак органнары, спорт федерацияләре һәм спорт объектлары җитәкчеләрен, шәхси бизнес вәкилләрен, журналистларны, спорт индустриясе экспертларын берләштерә.

Форум спорт өлкәсен үстерү планнарын формалаштыру, халыкара хезмәттәшлекне, халыкара спорт оешмалары, партнер-





лар белән элемтәләрне ныгыту, тәҗрибә уртаклашу, шулай ук балалар һәм яшүсмерләр спортын үстерү максатыннан оештырыла. «Россия – спорт мәмләкәте» форумы хезмәттәшлек турында бик күп килешүләр имзалау урыны да булды.

Мәсәлән, ДоброFON хәйрия программасы ПОДА Федерациясе белән төзелгән партнерлык хезмәттәшлеге турындагы килешүне озайтты. Нәтиҗәдә МХО ветераннары өчен берьюлы ике турнирны финанслау мәсьәләсе хәл ителде. Шулай ук «Импульс» III халыкара адаптив спорт төрләре фестиваленең дә партнеры булачак. Әлеге килешү инде фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы Алексей Ягудин тарафыннан кызыксыну уяткан. Шулай ук ПСБ банкы «Армиянең үзәк спорт клубы» (ЦСКА) һәм корпоратив спортны үстерү ассоциациясе белән хезмәттәшлек турында килешү имзалады.

Губернатор Вячеслав Федорищев билгеләп үткәнчә, бу чараны уздыру өлкә өчен быелгы иң мөһим вакыйгаларның берсе булды. Самар 25 елга беренче тапкыр Россиядән генә түгел, башка илләрдән дә күпсанлы кунаклар кабул итте.

– Илнең бөтен спорт җитәкчелеге ике көн дәвамында безнең төбәктә эшләде. Әлеге масштаблы форум легендалар, Олимпия чемпионнары, дөнья чемпионнары, федерация җитәкчеләре белән аралашу, безнең казанышларыбызны күрсәтү, спорт үсешендә яңа тенденцияләр турында белү мөмкинлеген бирде.

«Самара Арена» стадионында дроннар узышы буенча Россия Кубогы узды. Бу дроннарның стадионда узышы буенча беренче Россия чемпионаты иде. Бәйге федерациянең барлык кагыйдәләре буенча оештырылды. Әлеге спорт төре халыкта зур кызыксыну уятты. Шуңа күрә без Россиядә дөнья чемпионатын үткәрүгә гариза бирәчәкбез һәм, әлбәттә, форсаттан файдаланып, илнең спорт җитәкчелегенә мондый ярышлар Самарда уздырылсын дигән үтенеч белән мөрәҗәгать итәчәкбез. Чөнки нәкъ безнең өлкә илебездә пилотсыз очкычларны җитештерү үзәге булып тора.

Гомумән, “Россия – спорт мәмләкәте” форумы Самар өлкәсе өчен зур мөмкинлекләр ача. Ул балалар спорты өчен инфраструктураны киңәйтүдә дә зур адым. Форумга әзерлек вакытында без зур спорт объектлары: Тольяттида – Алексей Немов үзәге, Самарда Олег Сәитовның бокс сарае, футболны үстерү үзәге – академия һәм стадионнан 100 метр гына ераклыкта «Крылья Советов» базасы төзелеше турында игълан иттек. Ул клуб өчен генә түгел, бөтен футбол сөючеләр өчен дә ачык булачак, – дип ассызыклады өлкә башлыгы.

Йомгаклау көнендә кунаклар һәм масштаблы спорт вакыйгасында катнашучылар XV Юбилейлы Хәтер парадын карый алдылар. Ул гадәттәгечә Куйбышев исемендәге мәйданда узды. Быел парад сугыштагы спорт геройларына багышланган иде һәм өлкә башкаласы кунакларын үзенең масштабы һәм матурлыгы белән таң калдырды. Хәтер парадында Идел буе федераль округының 14 төбәгеннән, шулай ук Курск өлкәсеннән һәм Донецк Халык Республикасыннан килгән көч структуралары, хәрбипатриотик һәм тарихи клублар, хәрби уку үзәкләре, югары уку йортлары, кадет сыйныфлары, Суворов һәм Нахимов хәрби-диңгез училищелары, Яшь Армия отрядлары вәкилләре катнаштылар. Самарның үзәк мәйданы буйлап тантаналы марш белән 7,5 меңнән артык кеше узды.

Ә кичен Дмитрий Шостакович исемендәге опера һәм балет театрында РФ оборона министрлыгының Үзәк хәрби оркестры бәйрәм концерты тәкъдим итте.

# БУДЕМ ДЕРЖАТЬСЯ ВМЕСТЕ

**С 24 по 26 ноября в Казани прошел XVIII форум «Деловые партнеры Татарстана»**

***Ежегодно организаторами этого крупнейшего международного мероприятия, направленного на развитие делового сотрудничества и укрепление связей внутри татарского мира, выступают Всемирный конгресс татар при поддержке Торгово-промышленной палаты Республики Татарстан. На этот раз форум собрал более 400 предпринимателей из 10 стран мира и 58 регионов России. Участники форума обсудили экономическое развитие и инвестиционные возможности республики, перспективы совместных проектов, встретились с представителями органов власти и побывали на промышленных предприятиях и объектах инфраструктуры Нижнекамского района.***

***Данияр Сайфиев***

Республика Татарстан на протяжении вот уже многих лет занимает лидирующие позиции в рейтингах социально-экономиечского развития страны. А проводимый здесь ежегодный деловой форум, на мой взгляд, является лучшим примером того, как регионам нужно грамотно выстраивать свою инвестиционную политику. По словам руководителя Агентства инвестиционного развития РТ Талии Минуллиной, только в этом году объем инвестиций в республику составил порядка одного триллиона рублей, а объем налоговых доходов по итогам 2025 года прогнозируется в 1,7 триллиона. Понятно, что «Деловые партнеры Татарстана» – лишь малая толика той огромной ежедневной работы по привлечению и сопровождению бизнеса, которую Агентство проводит с момента своего образования в 2011 году.

## День первый. 2026 – Год Тукая

Татарское гостеприимство, как всегда, было проявлено на должной высоте. Все делегации разместили в «Корстоне», одном из лучших отелей и деловых центров Казани. Внутри этот комплекс сравним с разворошенным муравейником: везде снуют люди в костюмах с разнообразными бейджами, слышится иностранная речь, очень много волонтеров, помогающих гостям разобраться с возникающими вопросами. Видимо, для удобства участников форума деловую часть первого дня организаторы решили провести здесь же, в конференц-залах «Костона». 24 ноября здесь состоялось заседание Национального Совета Всемирного конгрес-









са татар. Его открыл заместитель премьер-министра Республики Татарстан, председатель Национального Совета Всемирного конгресса татар Василь Шайхразиев. Он поприветствал всех участников заседания и поблагодарил членов Милли Шура за поддержку наших соплеменников и укрепление культурных и деловых связей с Татарстаном. А говоря об итогах работы ВКТ, главными событиями уходящего года Василь Габтелгаязович обозначил выдвижение действующего руководителя республики Рустама Минниханова кандидатом на должность Раиса РТ и его убедительную победу на выборах, а также проведение в августе этого года в Казани «Миллэт жыены» («Национальное собрание»). Председатель совета также напомнил собравшимся, что в 2026 году исполняется 140 лет великому татарскому поэту – Габдулле Тукаю и 120 лет – поэту-герою Мусе Джалилю. Следующий год было предложено объявить Годом Габдуллы Тукая.

*– «Мы объявляем Год Тукая, однако при подготовке мероприятий мы будем помнить и о 120-летии со дня рождения поэта-героя Мусы Джалиля, а также о других значимых юбилеях выдающихся татарских деятелей»,* – подчеркнул Василь Шайхразиев.

Он также отметил, что это предложение было поддержано Раисом Республики Татарстан Рустамом Миннихановым в его жегодном послании.

После этого слово было передано руководителю исполнительного комитета ВКТ Данису Шакирову, который представил отчет о проделанной в течение года работе. Завершилось же заседание Национального Совета единогласным утверждением плана деятельности Всемирного конгресса татар на 2026 год.

В этот же день здесь состялось заседание дискуссионной площадки под названием «Экономика возможностей: Татарский бизнес-взгляд 2026». Перед стоящее повышение НДС, меры государственной поддержки, кадровый рынок, перспективы исламских финансов и вопросы устойчивого роста бизнеса. Особый интерес вызвала панельная часть, в которой предприниматели смогли не только услышать прогнозы и экспертные оценки, но и обсудить реальные кейсы, обменяться практиками и наметить возможные траектории сотрудничества. Завершился день командной практической сессией, направленной на формирование совместных проектов и поиск решений для работы в новых экономических условиях.



участниками форума выступили руководитель Агентства инвестиционного развития Татарстана Талия Минуллина, представители Торгово-промышленной палаты, Халяль-комитета и специалисты в области исламского банкинга. Эксперты обсуждали пред-

### День второй. Нижнекамск

Этот небольшой город по праву считается столицей нефтехимиков и поражает своей чистотой и опрятностью. Несмотря на то, что в городе проживает чуть менее 300 тысяч человек, практически 20% экономики республики





делается именно здесь, в Нижнекамске. По ключевым показателям социально-экономического развития Нижнекамский район стабильно входит в пятерку лидеров Татарстана. За 9 месяцев 2025 года инвестиции в основной капитал достигли 115 млрд рублей. Основными локомативами экономики безусловно являются компании «Сибур» и «Танеко», но также активно развивается малое и среднее предпринимательство. Инвесторам под новое производство, в случае успешного прохождения экологической экспертизы, здесь предлагаются промышленные площадки с уже подведенными коммуникациями. Из-за наличия огромного количества химических предприятий к вопросам экологии здесь относятся особенно трепетно. Участники форума побывали в крупнейшей в республике татарской гимназии имени Баки Урманчы, посетили предприятия и ознакомились с региональной экономической программой и успешными инвестиционными проектами муниципалитета. Одно из предприятий, на котором нам удалось побывать, это первый и единственный в России завод полного цикла по производству микрофибры «Bicotex». Здесь из гранулята делаются тонкие нити, из которых вяжется тканевое полотно. В год предприятие, на котором трудятся около 500 человек, выпускает 3200 тонн продукции.

Также предприниматели побывали в центре креативных индустрий «База», где самозанятые и представители малого бизнеса на льготных условиях могут арендовать помещения и развивать свое дело. Здесь же прошла панельная сессия, на которой делегатов познакомили с аспектами комфортной городской среды Нижнекамска, инициативами в области цифровизации и инвестиционным потенциалом муниципалитета.



## День третий. Заключительный

Главным событием форума стало пленарное заседание в отеле «Kazan Palace by TASIGO» с участием раиса Республики Рустама Минниханова. В нем приняло участие все руководство Татарстана, представители общественных объединений и бизнес-сообщества. Здесь были подведены итоги работы форума и определены векторы будущего сотрудничества.

Татарские предприниматели из разных регионов рассказали о своих бизнес-проектах, развитии деловых связей с Татарстаном, уделили особое внимание сохранению татарской идентичности. Выступил с докладом и член самарской делегации, директор «Мукомольного завода № 1» Рамиль Аюпов. Он рассказал о масштабной работе по поддержке участников специальной военной операции и их семей, а также о проекте строительстве нового корпуса самарской татарской школы «Яктылык» на 300 мест, поддержанной самарским правительством. Рустам Минниханов, поблагодарил власти Самарской области за поддержку этой инициативы, а самому Рамилю Идрисовичу за особый вклад в сохранение и развитие татарской национальной культуры и активную общественную деятельность вручил благодарственное письмо.

Раис республики подчеркнул, что ежегодные встречи в рамках форума «Деловые партнеры Татарстана» стали уже доброй традицией. Он отметил важность поддержания и развития связей с татарами из других регионов России и зарубежных стран.

*«Мы гордимся вами, многому учимся у вас. Вы – успешные предприниматели, которые уделяют большое внимание сохранению татарского языка, национальной культуры и традиций. Всем вам большое спасибо. Будем держаться вместе!»* – сказал раис республики.



# Мортазин укулары безгә үз-үзебезне яхшырак белергә ярдәм итәчәк

**Самарның Тарихи мәчете туган якны өйрәнүчеләрне һәм үткәннәренә битараф булмаган кешеләрне үзенә җыйды**

*“Башкалар белән бергә яхшы яшәр өчен бергәләп эш итү кирәк”. Бүген дә үз актуальлеген югалтмаган бу сүзләрне узган гасырның 20нче елларында Самар мәчете имамы Мөхәммәдфатыйх Мортазин Кырым газеталарының берсе өчен язган мәкаләсенә керткән булган. Әмма әлеге газета дөнья күрмичә калган.*

***Данияр Сәйфиев***

Быел Самарның кредит җәмгыяте әгъзасы, шәһәрдәге рус телле газеталарның штаттан тыш хәбәрчесе, Самарның танылган археолог В. В. Гольмстен җитәкләгән университеты каршындагы Археология, тарих, этнография һәм табигать белеме җәмгыяте әгъзасы, Россия империясендә “Икътисад” исемле беренче татар телле икътисадый журналга нигез салучы һәм аның мөхәррире Мөхәммәдфатыйх Мортазинга 150 яшь тулган булыр иде.

Самарның Тарихи мәчетендә бу вакыйгага багышланган тарихи-туган якны өйрәнү укулары узды. Әлеге чара, өлкә татар милли-мәдәни мөхтәрияте, “Туган тел” татар җәмгыяте, “Болгар мирасы” фонды ярдәмендә, шәһәребезнең татар тарихи туган якны өйрәнү җәмгыяте һәм өлкә мөселманнарының Региональ диния нәзарәте инициативасы буенча оештырылды.

2022 елда Тарихи мәчетне реконструкциядән соң ачу тантанасында өлкәбезнең ул вакыттагы губернаторы Дмитрий Азаров гыйбадәтханәне “Самара җирендә ислам энҗесе” дип атаган иде. Чыннан да, мәчет туган якны өйрәнү форумында катнашучыларны һәм кунакларны искитмәле матурлыгы белән каршы алды. Һәм аның тышкы ягы гына түгел, эчке бизәлеше дә гаҗәеп күркәм.

Әле күптән түгел генә гыйбадәтханәдә матур китапханә булдырылды. Ә Мортазин укулары үткән көнне биредә этнография музее беренче тапкыр үз ишекләрен ачты. Ни өчендер оештыручылар аны тыйнак кына “XX гасыр башында Самар мөселманнары көнкүреше” экспозициясе дип атаганнар.



Татар халкының тарихы, көнкүреше һәм тормышы турында сөйләүче экспонатларның барысын да диярлек музейга Самарда һәм өлкәбезнең татар авылларында яшәүче кешеләр тапшырганнар. Монда борынгы тимер сука (соха) да, сәер формадагы самавырлар да, борынгы тегермәннәр (жернова) һәм агач осталарының инструментлары да, күпсанлы тоткычлар (ухват), чуеннар да бар. Ә чигүле япма ябылган һәм чиккән тышлы мендәрләр тезеп куелган караваt күпләргә авылда әбиләре янында узган балачак вакытларын искә төшергәндер.

Бу экспонатлар күп еллар буе җыелып барган, һәм менә бүген алар, ниһаять, музейда лаеклы урын алдылар. Әйтергә кирәк, аны булдыруда һәм бизәүдә мәчет әһелләренә татар иҗтимагый оешмалары активисткалары һәм иганәчеләр булышканнар.

Укулар “Болгар мирасы” мәдәни-тарихи фонд инициативасы һәм ярдәме белән төшерелгән Идел буе Болгары тарихы турындагы фильмны күрсәтүдән башланды.

Аннары чарага җыелучыларны Самар өлкәсе мөфтие Талип хәзрәт Яруллин сәламләде. Форумда катнашучылар арасында милли һәм конфессиональ мөнәсәбәтләр өлкәсендә эш итүче галимнәр һәм белгечләр, өлкәнең төрле шәһәр-

ләреннән һәм районнарыннан килгән туган якны өйрәнүчеләр, мәдәният учреждениеләре һәм архивлар хезмәткәрләре, укытучылар һәм студентлар, милли-мәдәни берләшмәләр һәм мөселман дини оешмалары вәкилләре бар иде.

Талип хәзрәт Яруллин халкыбызның тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклауның мөһимлеген билгеләп үтте һәм



Мортазин укулары эшчәнлегендә барысына да уңышлар теләде.

Залда утыручыларны шулай ук Самарның старовер христианнары җәмгыяте рәисе Павел Половинкин, Ульяновск өлкәсенең татар мөхтәрияте рәисе, ТНВ телерадиокомпаниясе хәбәрчесе Рәмис Сафин сәламләделәр. Алар да үз тарихыңа сакчыл мөнәсәбәт күрсәтү, милли хәрәкәткә зур өлеш керткән шәхесләр турындагы хәтерне саклап калу зарурлыгын ассызыкладылар.

Рәмис Фәрук улы Самар татарлары башкарган эшләрнең күбесе илебезнең башка төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез өчен лаеклы үрнәк булып тора, дип билгеләп үтте. Ул шулай ук барлык кешеләрне өлкә “Бердәмлек” татар газетасын саклап калу өчен бөтен көчләрен куярга өндәде. Моның өчен аңа аерым рәхмәт.

Шуннан чара модераторы Шамил Галимов доклад ясаучыларга сүз бирде.

Шулай, имам Наил Биктаев чыгышыннан укуларда катнашучылар Тарихи мәчетнең үткәне һәм бүгенгесе, аның иҗтимагый һәм динара мөнәсәбәтләр системасындагы роле турында белә алдылар. Гыйбадәтханәнең 1891 елда ачылуы монда мәдрәсә һәм “Хәйрия” җәмгыятенең барлыкка килүенә ярдәм иткән. Мәчет татар һәм мөселман тормышының бер үзәге булган һәм хәзер дә шулай ук.

Тарихчы, Россиянең тарих җәмгыяте әгъзасы Александр Еремкин, карталардан файдаланып, безнең төбәктә булган атаклы вакыйга – 1931 елда Кондырча елгасы буенда Туктамыш һәм Аксак Тимер арасында узган сугыш турында сөйләде.

Ул бу сугышның төгәл урыны әлегә кадәр билгеле түгел, һәм галимнәр, археологлар әлеге юнәлештә эшләүләрен дәвам итәләр, дип ассызыклады.

Самар Идел буе топонимикасы турында сөйләгән тарихчы, туган якны өйрәнүче, журналист Шамил Галимовның чыгышы да бик кызыклы иде. Ул исемнәрендә төркитатар сүзләре ачык чагылган торак пунктлары һәм елгалар булуына унлаган мисал китерде. Бу – Кондырча, Сок, Кинел елгалары, Сызран шәһәре, Бинарадка, Ташла, Мусорка авыллары һәм башкалар.

Әлбәттә инде, Шамил әфәнде Самарның барлыкка килү датасына бәйле теманы да читләп үтмәде. Рәсми рәвештә шәһәребез 1586 елда нигезләнгән дип теркәлгән.

Әмма Галимов, Пицигани һәм Фра Мауроның борынгы карталарына таянып, Самарның тарихы тагын да борынгырак, дип саный. Шуңа күрә лингвистларга да, тарихчыларга да бу юнәлештә эшлисе бар әле.

Тарих фәннәре докторы Юлия Гусева Мөхәммәдфатыйх Мортазин тормышыннан кызыклы фактлар белән таныштырды. Менә сез, мәсәлән, аның 1920 елларда хатыны белән кинога баруы яисә “Ислам һәркайда да белем алырга куша” гыйбарәсен Мортазин әйткән дип саналуы турында белә идегезме?

Татарларның төбәкнең икътисадый үсешенә керткән өлешләре турында тарихи фәннәр докторы Наилә Таһирова сөйләп узды. Әлбәттә, аның чыгышында шәһәребез тарихында сизелерлек эз калдырган Акчуриннар һәм Баишевларның атаклы фамилияләре яңгырады. Ә бит безгә кадәр килеп җитмәгән тагын күпме күренекле исемнәр булган?

Иң ахырдан Самарның Җәмигъ мәчете имамы, туган якны өйрәнүче, китаплар авторы Иршат Сафин чыгыш ясады. Ул Куйбышев имамнарының 1940–1960 еллардагы эшчәнлеге турында сөйләде.

Кызганычка, форумдагы һәр чыгышны тәфсилләп бирер өчен журнал битләре генә җитми. Әмма аларның барысы да киңрәк яктыртуга лаек, шуңа күрә без Мортазин укуларында күтәрелгән бөтен темаларга да әле әйләнеп-әйләнеп кайтачакбыз.



Иң мөһиме – Самар татарларының тагын бер танып белү мәйданчыгы барлыкка килде, аның ярдәмендә без халкыбызның тарихын яхшырак белә һәм аңлый башлаячакбыз.

***В начале XX века его имя было широко известно татарам нашей страны и за рубежом. Ведь он открыл в царской России третью по счету газету на родном языке и первое такое же СМИ – в России советской. Под псевдонимом Камиль Мутыги наш герой стал одним из первых сценических исполнителей татарских песен и в течение 20 лет разъезжал по местам компактного проживания соплеменников, где давал концерты. Обладателя бархатного баритона охотно записывали на граммофонные пластинки иностранные фирмы. Кроме этого, Камиль Мутыгуллович Тухватуллин работал учителем и журналистом, редактором и драматургом, являлся активным общественным деятелем в сфере культуры и автором песен, а также книг. В течение года он трудился в Самаре, являясь заведующим подотделом печати губернского мусульманского комитета и губернской мусульманской организации РКП(б).***

***Рашид Шакиров***



# ЗНАТНЫЙ УНИВЕРСАЛ КУЛЬТУРНОЙ НИВЫ

Такая его энергичная «многостаночность» в мире искусств объяснялась не только поцелуями Всевышего, но и духом культуры, царившим в родительской семье благодаря ее главе – Мутыгулле хазрату. Этот уроженец села Малые Кайбицы Казанской губернии после получения образования в Кышкарском медресе в Заказанье, уехал в Египет и окончил за 10 лет лучшее на тот момент высшее учебное заведение – университет «Аль Азхар». А приехав оттуда, обосновался в городе Уральск (тат. – Жаек), где в конце 70-х годов XIX века открыл медресе «Мутыгия».

Учебные планы для заведения он составлял по своей методике, выделяя много времени естественным наукам и литературе. Хазрат обучал шакирдов даже строению стиха. Он организовал богатую библиотеку и выпуск рукописных газет и журналов. Ученики его медресе сидели не на полу, а за партами, Ученицами вскоре стали и девочки.

А в доме Мутыгуллы хазрата имела место быть настоящая творческая атмосфера, пробуждавшая у его детей интерес к наукам, поэзии, музыке и театру. Здесь проводились литературные вечера, а после овладения дочек домашним роялем – и концерты-экспромты. Их мама Гиззинас ханум вела занятия с хором, состоявшим из учениц медресе, и привлекла к пению своих четырех дочерей.

Детей у Тухватуллиных родилось много – 15, но в течение двух-трех лет из-за болезней их количество уменьшилось до семи. С Аминой, Халимой, Галией и Разией в семье росли три брата: Камиль, Гариф и Адгам (в некоторых источниках – Эдхем). Самым старшим ребенком стал герой этой статьи.

Он появился на свет 25 февраля (9 марта) 1883 года, и малой его родиной (как и всех братьев-сестер) значится столица Уральской области г. Уральск, входивший в Оренбургскую губернию (ныне – центр Западно-Казахстанской области



Республики Казахстан). Благодаря прекрасному домашнему образованию и природным данным (мог с одного раза заучивать тексты на татарском и арабском языках) Камиль к моменту поступления в отцовское медресе уже освоил курс обучения младших классов, и его определили параллельно заниматься в русских группах. В них он изучал русский язык, литературу, природоведение, географию



*С отцом, Уральск, 1890-е годы*

и окончил трехгодичную русскую школу с отличием. А в медресе «Мутыгия» юноша занимался до 16 лет и к моменту завершения учебы в нем овладел арабским, турецким, казахским, узбекским и чеченским языками.

Ләкин, ни кызганыч! Шатлык белән борчулар гел янәшә йөри, диләр. Озакламый солдатларга Чечняга сугышка китәргә, дигән фәрман килә.

Ике татар егете төрле эшелоннарда сугышка озатылалар. Һәм беркайчан да очраша алмыйлар. Тик снабжениедә хезмәт итүче егетләр аркылы бер-беренең хәлләрен белешеп, сәламнәр әйтешеп торалар.

Фаилгә дусты Мансурның сугышта батырларча һәлак булуы турында да шушы егетләр әйткәннәр. Зур фаҗигале хәбәрне ишетү Фаил өчен бик авыр булган.

Ул: «Әгәр исән калсам, Мансурның авылына барып, каберен зыярәт итеп, дога кылырмын», - дип әйткән булган.

Кызганычка, күп тә үтми, Фаил Габделнәфыйк улы бик көчле бәрелешләрнең берсендә каты яралана. Башта - Моздокта, аннары Самар госпиталендә бик озак дәвалана яшь солдат. Дөресен әйткәндә, үзе дә үлемнән кала.

Аннан соң, хезмәт срогын тутырып, туган авылына кайту



бәхетенә ирешә. Тик Мансурның төгәл адресын белмәү аның каберен зыярәт итүдән мәхрүм итеп тора.

Ә язмыш сугышта үлем белән кара-каршы очрашкан, батыр, көчле рухлы егеткә гомерлек мәхәббәт бүләк итә.

Беркөнне кичен, бераз йөреп кайтыйм әле дип, Фаил өйдән чыгып китә. Егет ерак китә алмый, күршеләре капкасыннан чыгып килүче бик матур кыз аның игътибарын җәлеп итә. Алар исәнләшеп, сөйләшеп китәләр. Кыз Гөлнара исемле икән.

Ә хәзер аның тормыш юлына күз салыйк әле.

Гөлнара Илгиз кызы Арча районындагы Иске Масра авылында өч балалы гаиләдә дөньяга килгән.

Әйтергә кирәк, Илгиз белән Кәүсәрия балаларын өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәткәннәр, хезмәт сөючән, үз алларына куйган максатларына ирешүчән итеп тәрбияләргә тырышканнар.

Әти-әнисенең матур үрнәгендә үскән Гөлнара балачагында укытучы булырга хыялланган. Шулай итеп, кыз Арча педагогика көллиятенең татар теле һәм әдәбияты факультетын кызыл дипломга тәмамлый һәм мәктәптә балалар укыта башлый.

Шул ук вакытта Казандагы гуманитар институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә читтән торып укый, аннан Сеҗе авылы мәктәбенә эшкә урнаша.

Гөлнара күршедә генә урнашкан Мөрәле авылында яшәүче туганнарына кунакка килеп йөри. Һәм биредә булачак тормыш иптәше Фаилне очрата да инде.

Яшьләр бик тиз уртак тел табалар. Сөйләшеп сүзләре бетми, очрашкан саен бер-берсеннән аерым яши амасларын аңлыйлар һәм вәгъдәләр бирешәләр. Бик озак та үтми, матур итеп туй уйныйлар.

Бераз гомер үткәч, яшь гаиләне тулыландырып, кызлары Гөлфинә дөньяга беренче аваз сала.

Әйтергә кирәк, Гөлнара каенанасы белән бик яхшы мөнәсәбәтләрдә булалар. Кызганыч, Флүрә апа гына озак яши алмый, мәңгелек йортка күчә. Ә озакламый аның улы Наил дә бакыйлыкка китеп бара...

Ә Фаил белән Гөлнара авылдан Казан шәһәренә күчеп урнашалар Биредә аларның уллары Әмир туа. Хәзерге вакытта ул алтынчы сыйныфта белем ала.

Ә Гөлфинә, мәктәпне тәмамлагач, нефтехимия көллиятендә һөнәр үзләштергән. Бүгенге көндә ул әтисе белән бергә авиация заводында эшли.

Гөлнара ханым шәһәрдәге моторлар төзү берләшмәсендә хезмәт итә.

Мин әңгәмәбез ахырында Гөлнарадан:

– Яшьли күп тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашкан, илебез алдында биргән антына тугры калган бүгенге Фаил нинди кеше? – дигән сорауны бирдем.

– Аллаһыга шөкер, ирем кешелекле, тәрбияле, яраткан балаларыбызга яхшы әти, ә миңа сөекле яр, тормыш итәр өчен яхшы ир, эшчән, итагатьле, якты чырайлы, үз алдына куйган максатына ирешүчән, – дип җавап бирде.

Ә мин язмамны төгәлләр алдыннан шуны әйтер идем: 25 ел вакыт үтеп китсә дә, Фаилнең безнең улыбызны онытмавы, аны зурлап, безне хөрмәт итеп, ерак араларны якын итеп, хәлебезне белергә килүләре өчен аларга чиксез рәхмәтләребезне җиткерәсебез килә.

Ә бүгенге көндә каты сугышларда кан койган ир-егетләрнең Әниләренә, улларын мәңгелеккә озаткан Аналарга:

– Әйе, балаңны югалту - әче әрну ул. Күпме еллар үтсә дә, күңелдәге яралар әле дә сызлый Шулай булса да, еламагыз әле, Аналар!

Безгә улларыбыз белән җәннәт түрләрендә очрашырга язсын!

Барыбызга да Аллаһы Тәгалә күркәм сабырлыклар бирсен! – дип әйтер идем.

# Булгары против монголов

*(Продолжение. Начало – в предыдущих номерах)*

**Как и почему погибло первое исламское государство в Поволжье**

***С точки зрения российской официальной истории события с 1223 по 1240 год, происходившие в Среднем Поволжье, и назвать-то трудно. Потому что в то самое время, когда на Древнюю Русь наших учебников напали безжалостные и ужасные «монголо-татары», рядом, на берегах Волги, эти самые монголы сражались… с предками тех, кого до сих пор в России зовут татарами. Получается какой-то оксюморон – монголо-татарская война…***

***Дмитрий ГРЕКОВ***



*Развалины Биляра*

## Биляр почти не виден

Потратив годы на войны с союзниками Булгарии – войны с кыпчаками, осады Саксина и Суммеркента – Бату и прочие правители Улуса Джучи решили сменить стратегию и нанести прямой удар. Летом или осенью 1232 года войско монголов направилось сразу на столицу вражеского государства – Биляр (называемый в русских летописях того времени «Великим городом»).

Единственным источником сведений об этих событиях является «Лаврентьевская летопись», сообщающая: «В лето 6740 (то есть 1232 года)… Придоша Татарове и зимоваша, не дошедшее Великого города Болгарьскаго…»

Историки считают, что монголы выступили из Приуралья, вдоль бассейна реки Шешма. Однако, судя по скудным данным источников, поход закончился ничем – увязнув в боях на границе и осадах крепостей, до Биляра оккупанты так и не дошли.

Скорее всего, какую-то роль (возможно, даже решающую) в провале этого нападения сыграло восстание кыпчакского племени кимаков (йемеков). Примерно в 1229 году некий Бачман из рода Олбурлик выступил против власти монголов. Писавший в XIII веке персидский автор Ала ад-дин Ата Малик ибн Мухаммед Джувейни в сочинении «Тарих-и джахангушай» («История мирозавоевателя») сообщал:

«Так как у него не было [постоянного] местопребывания и убежища, где бы он мог остановиться, то он каждый день [оказывался] на новом месте, как говорится, в стихе: „днем на одном месте, ночью на другом“, и из-за своего собачьего нрава бросался, как волк, в какую-нибудь сторону и уносил что-нибудь с собою. Мало-помалу зло от него усиливалось, смута и беспорядки умножались. Где бы войска [монгольские] ни искали следов, не могли отыскать его, потому что он уходил в другое место и оставался невредимым. Так как убежищем и притоном ему большею частью служили берега Итиля, он укрывался и прятался в лесах их, наподобие шакала, выскакивал, забирал что-нибудь и опять скрывался».

## Враг народа

К Бачману прибивались все недовольные монголами обитатели Великой степи. Дошло до самой столицы империи Каракорума – ха-

кан Угэдэй обсуждал с приближенными «опасение, как бы в степи не разбушевался неконтролируемый огонь, если тлеющие угли [сопротивления кыпчаков] не будут погашены».

Зимой 1235/1236 года против восставших кимаков был послан самый известный полководец монголов Субэдей. Как писал историк, Угэдэй «приказал чжувану Бату пойти в Западный поход на Бачмана, и еще сказал так: „[Мы] услышали, что Бачман имеет ловкость и отвагу, Субэдей тоже имеет ловкость и отвагу, поэтому сможет победить его“. Поэтому приказал [Субдею] быть в авангарде и сразиться с Бачманом, а затем назначил [его] командовать главной армией. После чего были захвачены жены и дети Бачмана на [берегу] Куан Тиен-чи-ссу [Каспийское море]. Бачман узнал о приходе Субэдтая, сильно оробел и сбежал».

Бачман отступил в дельту Волги, где монголы организовали на его отряд настоящую облаву, которой командовал один из Чингизидов – Мункэ.

По ее приказу соорудили 200 судов для контроля русла реки, в то время как сам Мункэ и его брат Бучек со всадниками прочесывали оба берега. Вскоре они нашли одну из сторонниц Бачмана, старую больную женщину, оставленную своими соплеменниками, и она рассказала, на каком острове прячутся беглецы.

В отсутствие лодок войска Мункэ не могли переправиться на остров. Но вдруг «поднялся сильный ветер и отогнал воду настолько, что остров стал достижим», после чего монголы напали. В последовавшей схватке они перебили численно превосходивших кыпчаков и захватили в плен Бачмана. Мункэ вернулся на берег реки со своим пленником, и «воды вернулись». Вождь повстанцев просил



лишь, чтобы Мункэ убил его собственной рукой, но тот отказался, приказав разрубить врага надвое брату Бучеку.

В этом рейде по низовьям Волги войска Мункэ захватили также аланов, которые, участвовали вместе с кыпчаками в борьбе против монголов. Аланского предводителя Качир Укуле взяли живым и предали той же казни, что и его кыпчакского союзника. Часть историков относят рейд Мункэ в поисках Бачмана и гибель последнего не к 1236/37, а к 1238 году.

## Курултай спешит на помощь

К 1235 году представители рода Джучи столкнулись с реальной проблемой – 11 лет войны на западных рубежах не принесли особых успехов и приращения земель. Монгольская летопись «Сокровенное сказание» констатировала: «Субеетай-Багатур встречал сильное сопротивление со стороны тех народов и городов, завоевание которых ему было поручено еще при Чингис-хане, а именно Канлин (Канглы), Кибчаут (Кыпчаки), Бачжигит (Мадьяры), Орусут (Русь), Асут (Асы-аланы), Сесут (Саксин), Мачжар, Кешимир, Сергесут, Булар (Булгария), Келет, а также и городов за многоводными реками Адил и Чжаях… Вражеских же стран там много, и народ там свирепый. Это такие люди, которые в ярости принимают смерть, бросаясь на собственные мечи. Мечи же у них, сказывают, остры…»

Проблему эти Джучиды решили примерно так же, как менеджеры АвтоВАЗа (или «ВКонтакте») – потребовали от Угэдэя «бюджетного вмешательства», то есть организации общемонгольского похода на запад.

Несмотря на «незакрытые» войны с Тибетом, Кореей и южным Китаем, хакан, чтобы не ссориться с большим кланом родичей, собрал в 1235 году большой курултай – съезд всех Чингизидов. На берегах реки Онон правители монголов приняли решение, о котором снова пишет знакомый нам историк Джувейни: «Когда каан [Угедей] во второй раз собрал Великий курилтай, они [царевичи] вместе совещались об истреблении и покорении всех оставшихся [до сих пор] непокоренными. Было принято решение о завоевании пределов Булгар, Ас и Рус, находившихся по соседству со становищем Бату, до сих пор не подчиненных и [тщеславно] гордившихся множеством своих городов».

# Разбойники, бандиты и неблагородные пираты

**О русско-булгарских войнах**

***Некоторые нынешние отечественные политики всерьез продвигают миф о том, что Россия-де никогда не вела завоевательных войн. Особенно против народов, входящих ныне в «братскую семью». Однако настоящая история — не та, которую каждый новый помощник президента переписывает в учебнике, а «та самая, которая ни слова, ни полслова не соврет» — всё помнит. В том числе и войнах Руси и Волжской Булгарии, которые даже войнами стыдливо не называют, говоря о каких-то «походах»...***

***Дмитрий ГРЕКОВ***



*(Продолжение.
Начало в предыдущих номерах)*

## Полет от Большого Гнезда

Всеволода Юрьевича, младшего сына Юрия Долгорукого, князя Суздаля и Владимира, романтически настроенные историки XIX века назвали Большим Гнездом (поскольку имел много детей). В конце XII и начале XIII века он был самым могущественным и влиятельным правителем на Руси, главой всех Рюриковичей. Неизвестный нам автор «Слова о полку Игореве» так описывал его: «Великий князь Всеволод! Не помыслишь ли ты прилететь издалека, отцовский золотой престол поберечь? Ты ведь можешь Волгу веслами расплескать, а Дон шлемами вычерпать». И вот в 1183 году Всеволод выступил в поход на Волжскую Булгарию.

По версии историка XVIII века Василия Татищева, в 1182 году «болгары волские… пришли в лодиях по Волге и берегом в области белорусские, которые около Городца, Мурома и до Резани великое разорение учинили». Поэтому состоявшийся в следующем году поход носил ответный характер.

Со Всеволодом также были полки иных городов и дружины других князей. Тогдашний киевский князь Святослав Всеволодович послал своего сына Владимира. Участие приняли также князь переяславский и племянник Всеволода Изяслав Глебович, смоленский князь Давыд Ростиславич послал сына Мстислава, из Рязани выступили князья Роман, Игорь, Всеволод и Владимир Глебович, из Мурома явился князь Владимир Юрьевич. Войско собралось у устья реки Оки, где погрузилось на корабли и двинулось далее вниз по Волге.

Войско дошло до места Исады, где полки и дружины высадились на берег, поместив корабли под охрану специально выделенного отряда – Всеволод оставил тут Белозёрский полк (ополчение из Белозёрска) с воеводами Фомой Незаковичем и Дорожаем. А вся остальная рать по суше, конными и пешими, далее двинулась к «великому городу серебряных болгар», как его называли летописи – Биляру.

## Мы будем брать Биляр!

Русская рать подошла к городу Тукчину, но штурмовать его не стала, а взяла в осаду. Два дня небольшой городок отказывался сдаваться, и на третий Всеволод решил идти дальше. Вскоре сторóжа (полевая разведка) сообщила, что впереди стоит булгарское войско. Готовясь к сражению, русские князья построились в боевой порядок.

Однако вместо вражеского войска показались половцы – князь

Емяк и его орда. Они тоже шли на булгар и предложили Всеволоду объединить силы. Князь собрал бояр и князей на совет, который решил принять помощь половцев. После чего объединенное русско-половецкое войско двинулось дальше. Перейдя реку Черемисан (Черемшан), русская рать подошла к Биляру и остановилась. Город был велик и защищен высокими стенами, множество окрестных булгар укрылись в нем, присоединившись к гарнизону.

Князь Всеволод снова стал советоваться с князьями и боярами, но тут ворота Биляра открылись и оттуда вышли вооруженные булгары. Молодой князь Изяслав Глебович, не дожидаясь приказа и подкрепления, со своей небольшой дружиной атаковал вражескую пехоту и обратил ее в бегство после короткой схватки. Князь, видимо, решил на их плечах ворваться в город и не прекратил преследование. Но у ворот атакующих встретили градом стрел – Изяслав был ранен в грудь. После всего этого совет князей и бояр принимает решение осаждать город, пока враги не сдадутся.

Летопись по «Воскресенскому списку» так об этом сообщает: «Изяслав же выгнав оплот ко вратом градным, и ту изломи копие свое, и ударише и стрелою во сердце сквозь бронь, и отъиде оттуду еле жив и несоша его во станъ».

Пока основная рать находилась у «великого города», булгары из Собекуля, Челмата и Торческа на кораблях пошли к Исаде, где остался русский флот. Они намеревались потопить вражеские лодки и отрезать русской рати путь домой. Пешие булгары сошли из кораблей на берег чуть выше русского стана, соединились с конницей и атаковали. Воеводы полков, что остались охранять лодки, выстроили ратников в боевые порядки и не дожидаясь приближения противника, сами пошли в атаку.


*Всеволод Большое Гнездо*

Схватка была скоротечной – не выдержав натиска противника, булгары побежали. Отступающих гнали до самого берега Волги, где аборигены поспешно погрузились на свои «учаны» и бежали, прием многие корабли от перегрузки перевернулись и потонули. Летописи сообщают (несомненно преувеличивая, и намного), что пошли на дно свыше тысячи «булгарских лодий».

## Худой мир лучше доброй войны

10 дней войско Всеволода осаждало Биляр, вести о сражении у Исады дошли и до князей, и до булгар. Сидевшие в городе поняли, что русские не отступятся, и решили начать переговоры. В лагерь коалиции князей прибыли булгарские послы. Был заключен мир. Условий договора мы не знаем, но он, очевидно, был выгоден для Всеволода Юрьевича – тот снял осаду и вернулся на Русь. На обратном пути было отправлено конное войско, которое разорило мордовские земли. Но удачное завершение похода омрачилось смертью Изяслава Глебовича, который умер в русском стане в Исадах.

Видимо, навязанный булгарам мир они соблюдали плохо – так что через два года, в 1185-м, Всеволод организовал новый поход, на сей раз без союзников.

О нем в «Лаврентьевской летописи» сообщается: «Того же лета посла великыи князь Всеволод Гюргевичь на Болгары воеводы свое с Городьчаны, и взяша [села] многы и възвратишася с полоном». Этот поход не имел большого размаха. Было взято несколько сёл, булгарские города в летописях не упоминались, на этом всё и закончилось.

Следует подчеркнуть, что центром подготовки военной операции, местом сбора и отправной точкой похода выступал недавно построенный Городец, в кампании участвовал в качестве самостоятельной единицы полк из этого города. Более того, некоторые историки настаивают, что «на этот раз войско состояло из одних городчан. Они тоже вернулись с победой. То, что Городец мог выставить собственную рать для похода, свидетельствует о многолюдности города».

# ТУГАН ЯККА ИГЕЛЕКЛЕ БУЛУ ИЗГЕЛЕКЛӘР ТУДЫРА



***Иске Балыклы авылы исемен ишетүгә, күз алдына балыкка бай күлләр, ярларына тулып аккан елгалар килеп басарга мөмкин. Ләкин монда андый елгалар да, күлләр дә юк. Тик шулай да, бу авылның төрле уйланулар тудыра торган серле исеме һәм шундый ук серләргә төренгән тирән тарихы бар.***

**Фәрид Шириязданов**

Төрле чыганакларда бу авылга нигез салучылар бирегә Татарстанның Арча районында урнашкан Балыклы авылыннан күчеп килгәннәр дигән хәбәрләр бар. Әлбәттә, Арча яклары – үзенең искиткеч бай табигате, тормышчан һәм чын татарлык күкрәп торган халкы белән танылган җирлек.

Менә Самар өлкәсендәге Камышлы районына кергән Иске Балыклы авылының да табигате матур, һәм ул урманнарга бай җирдә төпләнгән. Бу әле элгәредән белемгә тартылучан, киңкырлы сәләтләргә бай халкы белән дә танылган авыл.

Анда туып-үскән күп кешеләрнең элгәредән тирә-як авылларда да колхоз рәисләре, мәктәп директорлары, уку-укыту бүлеге мөдирләре һәм сәләтле укытучылар булып эшләгәне дә яхшы билгеле. Әлбәттә, болар шушы авылда элгәредән көчле интеллектуаль байлык тупланучы турында сөйли. Ни дисәң дә, ул юкка гына “Морзалар авылы” дип аталмагандыр шул!



Авыллар – тере субстанция. Һәр авылның үз язмышы, үзенчәлекле традицияләре, үзенә генә хас булган холкы–шөгыле һәм шуңа нигезләнгән яшәү көче була. Тик авыл үз халкын әйдәп барырга сәләтле лидерларны үзе тудыра һәм үзе тәрбияләп үстерә алганда гына, ул озын гомерле була ала.

Менә Әлмир Рафаил улы Нигъмәтуллинны да шикләнмичә шундый лидерларның берсе дип атарга була. Аның һәр башкарган эшендә үз нәселендә тупланган булдыклылык һәм башка матур кешелек сыйфатлары ачык күренә.

Хәзер күпләр төшенкелеккә бирелеп яшәгән вакытта ул, үз авылының киләчәген кайгыртып, кыю планнар корып, аларны тормышка ашыруга бар көчен куя. Якында ул үзенең яңа проектын гамәлгә ашырды – туган авылында зур буа корды.

Дөрес, монда зур су чыганагы булдыру теләге халык күңелендә элгәредән яшәп килгән хыял иде. Ниндидер вак-төяк буалар ясап карасалар да, көчле яңгырлар, язгы кар сулары аларны алып китә торды. Ә менә бу яңа буа ныклы итеп, уйланып, шартларына туры китереп эшләнгән.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк - Әлмирнең өченче бала булып улы туачагы беленгәч, куанычыннан ул шушы буаны төзү хакында нәзер әйткән иде һәм үз сүзендә торды да.

Дөрес, хәзер илдә зур корылышлар киң колач алып, тормыш тизлек белән алга барганда, бу авылда буа төзүне кайберәүләр вак мәсьәлә итеп кабул итәргә мөмкин. Тик төптән уйлаганда:

▷ ул - янгын чыккан очракта ашыгыч ярдәм чарасы;

▷ җәйләрен - су коену, кышларын бозда шуу өчен бер дигән корылма, исәнлек чыганагы;

▷ балык үрчеткән очракта ул әле Балыклы авылының исемен җисеменә туры китерү һәм аның тарихи исемен аклау рәвеше дә:

▷ хәзерге вакытта ул үз эченә генә бикләнеп, аптырауда яшәгән кешеләр өчен берләшү, күмәк фикер алышу чарасы һәм башкалар өчен матур изгелек үрнәге дә!

Хәзер күпләр сыкранып-сукранып, өметсезлектә пыскып яшәгәндә, Әлмир уттай янып, ялкынланып яши һәм эшли. Ул әле башкаларның йөрәгенә дә ялкын өстәп, киләчәккә өмет һәм матур итеп яшәүгә омтылыш тудырырга тырыша.

Әлмир Нигъмәтуллинның тормыш юлын күзаллаганда күп нәрсә гаҗәпләндерә һәм сокландыра: аның бар нәрсәгә кулы, вакыты, ихтыяр көче һәм күңел җылысы җитә.

Мәсәлән, Самар политехник университетында ул төрле яңа технологияләрне, фәнни ачышларны, инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешманың директоры булып эшли. Төрле заводлар белән тыгыз элемтәдә булып, ул яңа проектларны производство агымына кертү буенча киң колачлы эшләр алып бара.

Зур җаваплылык таләп иткән урында эшләвенә карамастан, ул авыл белән дә тыгыз элемтәдә





тора. Анда крестьян хуҗалыгы алып бара һәм җитмешләп баш мөгезле эре мал асрый. Моның өстенә, сиксән гектар җир эшкәртеп, аларга ризык әзерли.

Авыл хуҗалыгын алып баруның никадәр авыр, катлаулы хезмәт икәнен исәпләсәң, Әлмирнең мондый киеренке эшләр башкаруын ничектер акылга сыйдыру да авыр. Ул әле авылда, районда төрле спорт чаралары үткәрә һәм, оста спортчы буларак, анда үзе дә актив катнаша.

Әлмир Нигъмәтуллинның бабасы һәм әтисе – колхоз рәисләре булып эшләгән кешеләр. Бабасы – Гайзулла улы Хәбибулла Нигъмәтуллин - Камышлы районында гына түгел, Самар өлкәсендә дә олы хөрмәткә ия булган шәхес. Авыл хуҗалыгын алып барудагы уңышлары өчен ул «Знак почёта» ордены белән бүләкләнгән.

Аның оныгы булган Әлмир Нигъмәтуллинга да авыл хуҗалыгына карата тирән ихтирам һәм туган ягына олы мәхәббәт тумыштан бирелгән.

Быел авылда үзен депутат итеп сайлауны да ул горурланып кабул итте. Аның иң зур максаты – башка депутатларда да үз авылына карата хөрмәт уятып, үз авылының киләчәген бергәләп кайгыртуга күндерү!

Әлмир Нигъмәтуллин әле Иске Балыклы авылының бай һәм тирән тарихын саклау, үстерү һәм киләчәк буыннарга җиткерү буенча да төрле планнар кора.

Заманында Иске Балыклыны “Морзалар авылы” дип атауның сере биредә ундүртләп морзалар нәселе (татар кенәзләре) төпләнгән булуы турындагы истәлекләргә бәйләнгән.

Бу авылдагы җирләрнең кайсы гына почмагын алсаң да, аннан тирән тарих калкып, кычкырып тора. Монда яшәгән Йосыф Анкалышевны һәм Гавриил Давыдовны (Пугачёв генераллары булган) гына телгә алсаң да, алар турындагы истәлекләр таң калдыралар.

Гавриил Давыдовның унсигезенче гасырда Богырыслан өязеннән Рәсәй Дәүләт Думасына депутат булып сайлануы һәм аның Уложенная комиссия әгъзасы булуы гына да ни тора бит!

Туган авылының патриоты буларак, Әлмир Нигъмәтуллин үз нәселенең һәм авылының гыйбрәтле тарихы белән дә горурланып яши. Шулай да, Иске Балыклы авылының бүгенге хәле һәм аның киләчәге турында уйлаганда борчулы хисләр кичерә.



Авылны югалудан саклау, аның рухи халәтен үстерү юлында ул төрле планнар корып караса да, моңа күпләрнең битараф булуына йөрәге әрни.

Әлмир Нигъмәтуллин төзегән буа – Балыклы авылының гүзәл табигатен тагын да матурлап, андагы сүнә барган тормышка бертөрле җанлылык өстәде.

Суның һәм су чыганакларының күп серләргә бай һәм илаһи көчкә ия булуы борынгыдан билгеле. Туган яктагы җир-суларының тарту көче турында да күп сөйләнә, языла, һәм бу хакта күп җырлар да җырлана.

Бәлки, менә бу зур буа суы авылда туып, аның суларын эчеп үскән кешеләрнең дә тирәндә яткан хисләрен уятуга сәбәпче булыр. Аларда да, үз авылының хәлен аңлап, аңа нинди булса да изгелек эшләү, игелеклелек күрсәтү теләге уяныр дип ышанасы килә.

# ТАТАРЛАР – тарихта тирән эзле халык



*Татар тарихы кешелек яралган чорларга һәм әкияти заманнарга барып тоташа. Тик үз дәүләтчелеген югалткач, татарларны гасырлар буена дәүләтсез, күчмә тормышта яшәп, башкаларны талап көн күргән дала халыклары булганнар дип раслап килделәр. Ә чынында исә татарлар, дөнья тарихын тамырдан үзгәртеп, кешелек цивилизациясен уңай эзгә салырлык империяләр, гыйбрәтле дәүләтләр төзеп яшәгәннәр.*

**Фәрид Шириязданов**

Бу хакта мисалга Британия галиме Эдуард Паркерның “Тысяча лет из истории татар” исемле хезмәтен алырга була. Бу китапны борынгы Кытай чыганакларына таянып язгач, ул бөтен дөнья күләмендә бөек тарихчы-галим, тюрколог буларак танылa.

Эдуард Паркер биредә безнең эрага кадәрге 1нче гасырдан алып, безнең эрадагы 13нче гасырга кадәр булган татар тарихын яктырта. Үз гомерен ул төркиләр тарихын ачыклауга багышлый һәм искиткеч ачышлар ясый. Түбәндә аның “Тысяча лет из истории татар” китабыннан алынган мәгълүматлар бирелә.

Әле “төрк” сүзе кулланышка кергәнче мең ел элек тә кытайлар хиен-ну дигән кабиләләрне “татар” дип атаганнар. Бу безнең эрага кадәр 3 меңенче елларда, димәк, моннан 5 мең ел элек булган хәл дигән сүз бит!

Кытай чыганакларына таянып, Паркер Җания Баһадирның (Җания – Җаннар иясе) төньяк тунгусларның күпсанлы гаскәрен тар-мар итүе турында хәбәр итә. Ахырда аның дәһшәтле татар империясе башлыгы булуы, кытайларга каршы тиз арада 300 меңлек гаскәр туплый алуы һәм Кытай императоры аңа ясак түләп торуы турында яза. Җания Баһадир, “Утыз татар иле” башлыкларын бергә туплап, иң көчле империя төзи һәм ахырда бөтен Кытай империясен дә үз кулында тота.

Паркер Җания Баһадирның борынгы заманда кешелек тарихындагы иң бөек яу башлыгы булуы турында яза һәм аны “Татар Ганнибалы” дип атый. Җания Баһадир хакимлек иткән Дала империясендә ун миллионлап халык яшәгәнгә, Паркер аны шул чордагы иң гайрәтле һәм иң зур империяләрнең берсе дип саный.

Ул утыз ел гомерен татар тарихын җентекләп өйрәнүгә багышлый һәм тюркология фәненең асылын дөньяга таныту өчен үз гомеренең ахырынача көрәшә.

Чынында исә тарих өлкәсендәге “Европоцентризм” юнәлешендә галимнәр скифларны, сарматларны һәм башка дала халыкларын “ираноязычные” дип раслап килделәр. Ә төркиләр тарихы басылып аста калгач, ул, сансызланып, дөнья тарихының арткы планында торды.

Ә профессор Эдуард Паркер бер гасыр элек тә бу хакта менә нинди ачышлар ясый.

“Иксез-чиксез җирләрне биләгән күчмә халыклар: хиен-ну, скифлар, сарматлар, гуннар һәм башка төркиләр – барысы да хәзерге төр-

ки халыкларның, шул исәптән татарларның да борынгы бабалары булганнар!" – дигән дөреслекне исбатлый ул.

"Төркиләр" һәм "төркләр" дигән сүзләр нигезендә нинди серләр ята соң? Һәрбер сүзнең нигезенә тирән мәгънә салынган. Сүзләрнең никадәр зур көчкә ия булуы турында да күп мисаллар китерергә була. Менә "төрк" сүзен алсак та, аңа нинди серләр салынган соң?

Борынгы тарих чыганакларында "төрк" дип язылса да, хәзерге заманда "төрки халыклар", "төрки татарлар", "төрки болгарлар" дигән һәм башка атамалар еш кулланыла. (Түбәндә бу атама ничек язылса да, бу зур хата булмастыр кебек. Бәлки, тора-бара галимнәр моның да серен ачыкларлар әле).

Борынгы язмаларда кулланылган "Күк төркләр" дигән атаманың мәгънәсенә төшенү өчен, иң беренче чиратта, төрки илләрнең идеологиясен аңлый белү кирәк. Мәсәлән, Зәңгәр Күкне борынгылар астрономик төшенчә буларак кына түгел, ә бар нәрсәне тудыручы, булдыручы Бөек Тәңре – Ходай итеп кабул иткәннәр, ә үзләрен Күктән иңгән халык яисә Күк Төркләр дип санаганнар (Небесные тюрки). Әлбәттә, бу бик тирән философиягә нигезләнгән инану рәвеше. Моның серләрен аңлар өчен тирән тарихка күз салырга кирәк.




Татар тарихы турындагы борынгы чыганакларда "төрк" сүзенең мәгънәсе мифология белән тыгыз бәйләнгән. Ә хәзер без "мифлар" дип кабул иткән борынгы төркләр философиясе тирәндә яткан галәм серләренә нигезләнгән.

Мәсәлән, "төрк татар", "төрк болгар" кебек сүзләргә Күк төркләрнең җан түрендә куркусыз һәм зур көчкә ия булган "кот" (дракон – космическая сущность) утыра дигән мәгънә салынган.

Элгәре кемдер курыккан вакытта "котым алынды", "котым очты", "котым ботыма китте" дигән сүзләр еш ишетелә яисә куркак, мәгънәсез кешене "котсыз", "затсыз" дип атыйлар иде.

Болгар бабаларыбызның байракларында, хәтта хәзерге Казан символикасында да аждаһа сурәтләнүе очраклы хәл түгел. Хәзерге вакытта да Кытай, Сингапур, Вьетнам, Япония һәм башка Көнчыгыш илләрендә яшәгән халыкларда да драконның сулышы көчле космос энергиясе чыганагы, илаһи көч дип исәпләнә. (Ә фэншуй – шул ук дракон сулышын яисә космос энергиясен үзеңә тартып, көч туплау рәвеше).

Төрки халыклардагы "кот" сүзе – аларның куркусызлыгын, батырлыгын һәм бөеклеген тәшкил иткән серле төшенчә. Чыннан да, төркиләр, Евразия җирләрендә җиде көчле империя корып, кешелек тарихын уңай эзгә салганнар. Хәтта иң гайрәтле Рим империясен дә тармар итеп, алардагы колбиләүчелек кебек кыргый сәясәтне юк иткәннәр һәм Европада мөстәкыйль илләр төзелүгә юл ачканнар. Рим Папасы да аларны "Небесные воины", "Бич Божий" дип атаган.

Төркиләр җан һәм тән тәрбиясенә аеруча зур игътибар биргәннәр. Мәсәлән, куркку зур җинаять саналган. Балаларын 3–4 яшьтә үк атта чабарга, ә 9–11 яшьтә коралларны оста итеп кулланырга өйрәткәннәр. Ә 13–14 яшьтә алар инде сугышларда катнашканнар. Куркусыз һәм көчле булганга, төркләр үзләреннән ун тапкыр күбрәк санлы дошманнарны да җиңә алганнар! Сан белән түгел, ә искиткеч көчле рухлы булулары белән!



*Дракон – космик асыл*

Сугыш стратегиясе осталыгы белән бергә алар дипломатия өлкәсендә дә оста сәясәтчеләр булып танылалар. Сәясәт һәм сәүдә өлкәсендә эшләр алып бару өчен төрле илләр белән илчелекләр дә алышканнар.

Борынгы төркләр корган дәүләтләр, көчле империяләр нинди үзенчәлекләргә ия булганнар соң? Күк төркләрнең дәүләт төзелеше, идеологиясе, мәдәнияте, шул халыкның рухи халәте, дөньяга карашы һәм этногенез үзенчәлекләре – барысы да тормышны галәм законнарына тиңләп алып баруга нигезләнгән. Менә шундый идеологиягә нигезләнгән сәясәт шул заманнарда кешелек тарихын тамырдан үзгәрткән дә инде.

Хәзерге гади генә булып тоелган тормыш итү күренешләре, уңай яшәү кагыйдәләре Күк Төркләр үрнәгеннән башлана һәм хәзергәчә дәвам итә.

Ил белән уңышлы идарә итү өчен төркләр аны олысларга бүләләр (область).

Хөкүмәт идарәсе дә өч тармакка бүленә: Үзәк (палата), уң канат (тардуш) һәм сул канат (толес). Ил белән Каган идарә итә. Ул Ашина нәселеннән сайлана. Каган шулай

ук гаскәр башлыгы, судья һәм дин башлыгы да булып санала.

Түркләр, Тәңрегә табынудан башка, буддизм, христиан дине, иудаизм һәм ислам диннәре белән яхшы таныш булып, кем кайсы дингә инанырга тели – шуны кабул иткән. Алар Гарәп хәлифәте, Персия, Византия, Индия һәм Кытай халыкларының культуралары белән дә танышалар.

Күк түркләр дөньяның яртысын яулап алырлык гайрәтле армия һәм шул җирләрне кулда тотарлык көчле дәүләтләр төзиләр. Алар дөньяда беренче булып ат өстендә сугышу өчен ияр уйлап табалар.

Нәтиҗәдә сугыш стратегиясе тамырдан үзгәрә. Коралы көчләрнең төп өлешен кавалерия тәшкил иткәч, алар коралларын да ат өстендәге сугышка көйлиләр. Армия белән идарә итү принцибын да тамырдан үзгәртеп коралар. Гаскәрләр унлыкларга, йөзлекләргә, меңлекләргә һәм ун меңлекләргә бүленә. (Хәзерге вакытта бу тәртип дөньядагы барлык илләрдә дә кулланыла).

Күк түркләр үз балаларын өч яшьтән чын сугышчы булырга әзерли башлыйлар. Физик яктан чыныгу белән бергә рухи чыныгуга да зур әһәмият бирелгән. Аларның идеологиясе Тәңре философиясенә нигезләнгән. Куркаклык Тәңре каршында иң зур гөнаһ һәм хыянәт саналса, батырлык иң югары дәрәҗә һәм хөрмәтле гамәл булып саналган. Алар балаларын кечкенәдән үлемнән курыкмаска өйрәтеп, көчле рухлы итеп тәрбияләгәннәр.

Күк түркләрнең Кытай, Иран, Византия һәм Гарәп хәлифәте кебек бөек империяләр белән барган зур сугышларда җиңүләр яулавы аларның көчле рухлы, җиңелмәс халык булуы турында сөйли.

Күк түркләрдәге дәүләт идеологиясе, хәрби көчләр төзелеше, сәясәт һәм икътисад өлкәләрендә шактый алга китүе – барысы да көчле рухи тәрбиягә бәйләнгән.

Күк түрк империясенең цивилизация юлындагы үсеше, Бөек Ефәк юлын үз кулына алып, күчмә тормыштан утрак тормышка күчкәч, малчылык, кырчылык, һөнәрчелек һәм башка хуҗалык өлкәләрендә ирешкән уңышларына да бәйләнгән. Шулай ук Күк түрк империясенең төп казанышы – Кара диңгездән Атлантик океанга кадәр җирләрдә яшәгән тугандаш халыкларны бергә туплап, аларның рухи культурасын һәм көнкүреш шартларын югары күтәрү.



*Тарханлык грамотасы*

Беренче Күк түрк империясенең ирешкән казанышлары киләчәктә башка дәүләтләрнең ныклы үсеш алуына да сәбәпче булалар. Алар фән һәм культура өлкәсендә дә югары уңышка ирешәләр:

▷ тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгән календарьлар төзиләр,

▷ сан һәм вакыт исәпләү системаларын булдыралар,

▷ метрология, космогоник карашлар нигезендә төрле ачышлар ясыйлар (галәм серләрен өйрәнү өлкәсендә),

▷ философия һәм дөньяга караш та югары үсеш ала.

Гомумән, борынгы түркләр ачкан галәм серләренең күбесе әле бүген дә күп сораулар тудыра.

Күк түркләрнең дәүләтчелек нигезе кешенең туган җирен, табигать күренешләрен, ата-бабаларының рухын, үз иленең тарихын изгеләштерүгә нигезләнгән.

Бу аларның дәүләт идеологиясе нигезендә яткан һәм кешедә патриотизм тәрбияләү рәвешенең төп принцибы булган. (Мәсәлән, төркиләрдә, кеше үлгәч, өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәрү, догалар кылу гадәте).

Төркиләрнең дәүләт төзелеше принциплары гаделлеккә, каганның һәм югары катлам вәкилләренең үз халкы белән уңай мөнәсәбәтләрдә булуга, үзара булган хөрмәткә нигезләнгән.

Дәүләт башлыгы – каганның төп вазыйфасы булып үз илен саклау һәм аны киңәйтү, халкының көнкүреш шартларын кайгырту, илнең дәрәҗәсен һәм данын үстерү кебек мәсьәләләр торган.

Каганга куелган таләпләр: ул зирәк, батыр, гадел, туры сүзле булырга тиеш.

Халыкка карата булган таләпләр: тәртипне төгәл саклау, үз вазыйфаларын һәм кушканны төгәл үтәү, буйсынып яшәү.

Югары катламдагы бәк (князь) титулы гомерлеккә һәм нәселдән-нәселгә бирелмәгән. Аны тик яуларда – батырлык, дәүләт идарәсе эшендә булдыклылык күрсәткән, сәясәттә һәм башка өлкәләрдә уңышларга ирешкән өчен биргәннәр.

Гомумән, каган, бәкләр һәм элита вәкилләре халык алдында ил язмышы өчен тулы җаваплылык тоеп яшәргә тиеш булганнар.

Каган Күл Тәгингә куелган һәйкәлдә аның исеменнән киләчәк буыннарга атап мондый юллама язылган:

“Мин үз халкым өчен төннәрен йокламадым һәм көннәрне бушка уздырмадым – үз халкымны кайгыртып, ил бөтенлеген саклап яшәдем. Сугышларда батырлыклар күрсәттем.

Ач, ялангач халыкны тук һәм житешле тормышта яшәтер өчен бар көчемне бирдем, аларда киләчәккә ышаныч тудырдым. Хәерчелекне бетердем һәм азсанлы халык күбәйсен, башкалар да безгә

килеп кушылсын, дәүләтебез бай һәм көчле булсын өчен бар булган мөмкинлекләрне дә кулландым!"

Төркләрнең дәүләт төзелеше, аның хокук системасы (Законодательство) аларга Тәңредән иңдерелгән Түрә канённарына нигезләнгән. Алтын Урда дәверендә бик борынгы "Түрә" нигезендә Чыңгызханның "Яса" хокук кодексы барлыкка килә. Анда әле башка илләрнең дә борынгыдан билгеле булган хокук кануннарыннан кайбер кыйммәтле мәгълүматлар кулланыла.

Ясага беренче чиратта Чыңгызхан үзе буйсына. Аның таләпләре катгый, ләкин дә гадел һәм тормышчан була.

Андагы таләпләр:

▷ бар булган диннәргә дә хөрмәтле караш,

▷ алардагы дин башлыкларына киң ирекләр бирелә, һәм алар салымнардан азат ителәләр,

▷ җәмгыятьтә гаилә бөтенлеген саклауга зур әһәмият бирелә,

▷ үз иленә мәхәббәт, батырлык күрсәткән, ярдәмчел кешеләргә иң югары дәрәҗәдәге хөрмәт күрсәтелгән,

▷ караклык, ялган, дәүләткә каршы җинаять эшләгән өчен иң каты җәза каралган.

Гомумән, Яса кануннарында тормыш алып баруның бөтен кагыйдәләре дә язылган. Ул белекләргә һәм ярлыкларга нигезләнгән.

Белекләр – тормыш тәҗрибәсенә нигезләп тупланган белем һәм акыллы киңәшләр җыентыгы. Алар Алтын Урдада хокук системасы кодексын һәм хөкүмәт эшчәнлегенең нигезен тәшкил иткәннәр.

Ярлыклар – Яса принциплары белән беррәттән хан ярлыклары да закон көченә ия булган. Ислам кабул ителгәч, аларны Шәригать суды алыштыра, һәм хан ярлыклары "Жалованные грамоты"га әверелә. Ярлыклар булып шулай ук "Тарханные грамоты" хезмәт итә.

Дәүләт идарәчелегендә тамга системасы да киң кулланышта булган. Тамга – дәүләтчелек символы. Ул шулай ук ханның мөһере (печате) булып та хезмәт иткән. Акча сукканда аны кулланганнар, шулай ук товарларга куйганнар һәм дәүләт эшлекләләре товар салымы алганнар, хәзерге таможнялар сыман. "Таможня" – тамга сүзеннән.

Тарханлык язуы (Тарханная грамота) – шундый ук дәүләтчелек, идарә итү символы.

Сәидләр, ислам динен кабул иткәч, дин башлыгы буларак, дәүләт идарәсе системасында зур урын алып, иң җаваплы эшләрне башкаралар. Мәсәлән, хан булмаган вакытта аны да алыштыралар, хәтта сугыш вакытында гаскәрләр белән дә җитәкчелек итәләр. Сәидләр, ханнарның киңәшчеләре булу белән бергә, әле дәүләт башлыгы (премьер-министр) кебек рольне дә үтиләр.



*Алтын Урда әләмнәренең берсе*

Казыйлар, дәүләт законнары һәм тәртип сагында тору белән беррәттән, ил халкы тормышының барлык тармакларында да шәригать кануннарының төгәл үтәлүен тикшереп, гаепплеләрне җәзага тарталар.

Алтын Урда дәүләте таркалгач, аңардан соң барлыкка килгән барлык дәүләтләрдә дә Жучи олысында булган дәүләтчелек принциплары, хокук системасы һәм дәүләт башлыкларын сайлау тәртибе унтугызынчы гасырга кадәр тулысынча саклана.

Россиянең дәүләт буларак оешуы Алтын Урда канаты астында, аның принциплары нигезендә барлыкка килә.

Урда таркалгач, аңардан соң барлыкка килгән дәүләтләр арасында Рус дәүләте, иң көчлесе булып, тора-бара анда барлыкка килгән бөтен дәүәтләрне дә буйсындырып, Алтын Урда җирләренә хуҗа була. Рус дәүләтенең "Русская правда" дип аталган беренче хокук системасы да "Яса"га һәм православие дине кануннарына нигезләп төзелә.

Борынгы төркләрнең безгә калдырган рухи мирасы искиткеч бай, аны танып белергә генә кирәк. Мәсәлән, Зәңгәр Күкнең синонимнары булган "Осман", "Ор" атамаларында тирән серлелек ята. Осман империясе, османлы төркләр – шул ук "Күк төркләр" төгелме соң?

Ор елгасы буенда урнашкан Орск, Оренбург шәһәрләренең исеме кайдан килгән? "Орден" сүзенең нигезендә нинди мәгънә ята?

Ор дан – ул дан казанган кешеләргә Күк тарафыннан, Ордан бирелгән бүләк диган мәгънәдә түгелме соң?

"Байрак", "әләм" төшенчәләрендә дә Күктән көч, энергия алу рәвеше кебек мәгънә салынган. Байракны югалткан яисә аска каратып тоткан кешене үлем җәзасы көткән, чөнки моны Күк белән ара өзелүгә тиңләгәннәр (Парадта фашистларның байракларын аска каратып җиргә ташлау – аларның рухын сындыру рәвеше).

Төркләрнең тормышчанлыгы, көчле рухлы, җиңелмәс халык булуы һәм пассионарлыгы аларның көчле рухлы булуына, идеологиясенә бәйләнгән. Ә болар, үз чиратында, тирән философиягә нигезләнә.

Төркләр философиясе, борынгы кытайлар һәм япон самурайлары философияләре кебек, тирән мәгънәле, мавыктыргыч, серле һәм матур. Тик аны борынгы китаплардан укып аңлау – авыр мәсьәлә.

Төркләрнең сигез кырлы йолдызын гына алсаң да – ул иң серле күренешләрнең берсе. Аны сәяхәтчеләр һәм суфилар йолдызы, җәмигъ йолдыз, җидегән йолдыз, казык йолдыз дип тә атыйлар.

Аның билгесен бөтиләргә, кыйммәтле әйберләргә, йөзекләргә, төрле бизәкләргә дә куялар.

Бу күренеш андый тамга салынган җиргә шайтан кагылмый дип инануга бәйләнгән.

***Сөйләшеп утыруы да бик рәхәт аның белән. Тормыш тәҗрибәсе зур, күңеле риясыз, бөтен кешене мактый, һәркемне хөрмәт белән искә ала. Шул ихлас күңеле, холкының гүзәл сыйфатлары өчендер, мөгаен, бәхетле тормыш нәтиҗәсенә ирештергән аны Бөек Аллаһы!***

***Суфия Сәлимова.*** *Гали авылы, Похвистнево районы.*

# МАКСАТЫНА ИРЕШКӘН БӘХЕТЛЕ АНА

Сүзем Похвистнево районының Гали авылында гомер кичергән Әклимә Шәрипҗан кызы Мостафина турында бара. Кызганыч ки, хәзер язмам герое якты дөньяда юк инде. Аның тормышының мәгънәсе оя коруда, балалар үстерүдә, аларга лаеклы тәрбия бирүдә булган. Нур сибеп тора торган чын татар хатын-кызы иде ул!



*Әклимә Мостафина*

Әклимә ханым турында ишетеп белсәм дә, аның белән якыннан 2005 елда таныштым мин. Укытучы буларак, үз сыйныфым балалары белән “Мәктәптә ял почмагы” дигән проект өстендә эшли идек. Ә аны башкарып чыгар өчен матди мөмкинлекләр кирәк. Әклимә апа бу турыда каян ишеткәндер, беркөнне безне үзенә чакырып алды. Классымдагы барлык укучылар белән аңа барып кердек. Аның нурлы күзләре, якты йөзе, йомшак итеп эндәшүе күңелләрне эретеп җибәрде. Ул безгә проект өчен әллә ничә тәрәзә гардины бирде һәм бераз акчалата да ярдәм итте.

Укучылар белән дә бик яхшы сөйләште Әклимә ханым. Кайсысының кемнең баласы икәнен белеште, мәктәптәге укулары, проектыбыз турында сорашты, шул эшләре өчен мактады, изге теләкләр теләп, озатып калды. Малайлар, кызлар да бик шатландылар, күтәренке кәеф белән кайтып киттеләр.

Соңрак без укучылар белән тагын бер социаль проектка керештек. Аның максаты авылыбыз кешеләрен Морат бабкай чишмәсен чистарту, төзекләндерү проблемасына җәлеп итү иде. Бу мәсьәлә белән күп йөрдек без. Район җитәкчеләренә кадәр барып җиттек. Алар чишмәне килеп карадылар да: “Монда милиораторлар, махсус техника һәм бик күп акча кирәк. Тик район казнасында андый акча юк”, – диделәр. Кәефебез төште, әлбәттә.

Март аенда авыл клубында мәктәп балалары катнашында Хатын-кызлар көненә багышланган концерт узды. Шунда мин авылдашларга чишмәбез турында сөйләдем. Балаларның гына көче җитмәвен, бу эшкә берләшеп керешергә кирәклеген, матди яктан зур ярдәм таләп ителүен аңлаттым.

Ул концертта Әклимә апа да булган, өенә кайткач, бу турыда балаларына сөйләгән. Ә алар, әниләренең киңәшен тыңлап, кичектермичә бу эшкә керештеләр. Әнине хөрмәт итүнең, яратуның чын дәлиле менә шушы инде ул, минемчә.

Ничек оештырганнардыр, техникасын кайдан тапканнардыр, әмма инде җәен чишмәбезнең сулары агып китсен өчен канаулар да ерылды, тирә-ягындагы сазлыклар да киптерелде, сулары да чистартылды.

Галинең тагын әллә ничә егете бу эшкә үз өлешен керттеләр. Соңрак әле тагын бер игелекле авылдашыбыз – Дания ханым Тулова чишмәне тагын да матурайтырга ярдәм итте.

Әклимә апага, ул үстергән балаларга һәм шушы игелекле гамәлдә булышкан һәркемгә күпме кеше рәхмәт укый, дога кыла хәзер!

Әйе, Әклимә ханым бәхетле ана булды. Балаларының барысы да тырыш, миһербанлы, шәфкатьле, гадел һәм саф күңелле.

Ә бит Әклимә апа гел рәхәттә яшәмәгән. Бу көнгә ирешкәнче, аңа күпме нужа күрергә, тир түгәргә туры килгәнлеген аңлар өчен аның тормыш юлына күз салырга кирәк.

Әклимә ханым 1941 елда, Шәрипҗан ага белән Әсма апа гаиләсендә, Әнисә, Суфия, Мәдинә, Рәйсә апалары артыннан бишенче бала булып дөньяга килгән. Аңа 8 яшь тә тулмаган булган, әтисе бакыйлыкка күчкән.

Әклимә ханымның бертуганы Рәйсә апа болай дип исенә төшерә:

“Әткәйнең төсе һәм бер вакыйга гына истә калган. Ул чирләгәндә алар инәкәй белән Богырысланга табибка күренергә киттеләр. Кайтышлый Благодаровка авылы ки-

бетенә кереп, сумка сатып алганнар. Әти шунда миңа: “Сумка бирәү генә иде шул, Әклимә беренче сыйныфка бара бит, аңа булсын инде, кызым. Ә сиңа инәң матур букча тегеп бирер”, – дигән иде”.

“Үләсен, иң кече кызы Әклимәсенең бик яшьли ятим каласын сизгән, күрәсең”, – дип сүзгә кушылдым.

“Әйе, шулайдыр инде. Үлемнән, аннан соң сорау алудан курка иде

Ул заманда табынны идәндә коралар иде бит. Самавырны да шунда куябыз. Шулай, беркөнне дүрт яшьлек Ильяс иркәбез йөгереп килде дә самавырга абынды. Нәзек җирен пешереп, тиз арада үлеп тә китте. Шуңа бик әрнеште инде әткәй. Төпчегенә өй салырга җыенган иде бит ул. Урманчыларга бүрәнәләр өчен акчасын да биреп куйган булган. Үзе үлде, акчалары югалып калды, кайтарып бирүче булмады”.



*Миргазиз һәм Әклимә Мостафиннар*

ул, – дип сөйләп китте Рәйсә апа. – Авырса да, мәчеткә йөрде. Җомга саен Котлыәхмәт мулланы өебезгә чакыра иде. Аңардан үзенең каберендә “тыну”ын сораган булган. Элгәре бит “тыну” – кабер өстенә ятып куну бар иде. Котлыәхмәт мулла бик сирәк кешегә генә бу гамәлне кыла торган булган.

Әткәйне җирләгәч, икенче көнне иртүк безгә килде Котлыәхмәт абзый. Аның: “Тындым. Мин укып яттым, ә аннан тонык кына тавышлар ишетелеп торды. Әтиегез тынычланды. Курыкмагыз, беркая да йөрмәгез. Чәегезне куегыз, эчегез, ашагыз, өегездә торыгыз”, – дигәне әле дә исемдә.

Әткәй үләр алдыннан иң олы Әнисә апабыз малай тапты. Әткәй аңа вафат булган иркәбез истәлегенә Ильяс дип исем куштырды.

Сугыш арты еллары бит бу. Авырлыкларга да, ятимлек ачысына да түзгәннәр, яшәргә тырышканнар. Сынаулар аларны нызыткан гына.

Әклимә апа мәктәптә яхшы укыган. Ике классташы – Наилә Шаяхмәтова һәм Нәсимә Манашева белән якын дуслар булганнар алар. Аралашканнар, серләшкәннәр, бер-берсенә куна йөргәннәр.

“Күбрәк Әклимәгә бара идек инде. Әтисе юк, Әсма апа көнбагыш сатарга китә. Без дәресләр әзерлибез, кулъяулыклар чигәбез, төрле кул эшләре белән шөгыльләнәбез.

Безнең янга әткәй төшә, китап укып утыра, аннары бездән ишекләрне бикләтеп, кайтып китә иде”, – дип исенә төшерә Нәсимә ханым балачак елларын.

Әклимә акыллы, уңган һәм бик чибәр кыз булып үсеп җиткән. Сигезенче сыйныфны тәмамлагач, әнисенә ярдәм булсын дип, апалары янына Үзбәкстанга эшкә киткән.

Әклимәнең булачак ире Миргазизгә дә тормыш камчысы каты суккан. Керосинкада аш пешергәндә әнисенең күлмәгенә ут капкан. Сүндерә алмагач, ул урамга чабып чыккан. Бу вакыйга турында: “Әле дә күз алдында тора. Тере факел булып, кычкыра-кычкыра йөгерде. Аннары йорт турларындагы яңгыр күлдәвегенә ташланды. Тик бу ярдәм итмәде. Кемдер аның өстенә юрган чыгарып япты. Без, ул вакытта урамда уйнаган бала-чага, тораташ булып каттык да калдык.

Табиблар булыша алмаган. Ике көн дигәндә, ире Миннегазизне һәм дүрт баласы – Миргазиз, Фәнүзә, Фәния, ике яшьлек Җәүдәтне калдырып, дөнья куйды бичаракай”, – дип сөйләгән иде Ильяс абый Арысланов.

Бераз вакыт үткәч, Миннегазиз абый өйләнгән. Тик күптән түгел әниләрен югалткан балалар – Миргазиз, Фәнүзә һәм Фәния үги ананы кабул итмәгәннәр. Бәлки, яшь әни дә алар белән уртак тел тапмагандыр, кем белә...

Әтисе һәм үги ана белән ике яшьлек Җәүдәт кенә калган. Ә Фәнүзә белән Фәния, Үзбәкстан якларына китеп, анда кияүгә чыкканнар, шунда яшәп калганнар. Авылга кайтып-китеп кенә йөргәннәр.

Миргазиз исә, җиденче сыйныфны тәмамлагач, иптәше Ильяс Арысланов белән Куйбышевтагы ФЗУга юл тоткан.

Бу турыда Ильяс абый: “Поезд баскычына утырып киттек без. Миргазиз бик моңлы иде. Ул җырлый, мин кушылам:

Сау бул, Алькин, китәм синнән,
Син дә туйдыңмы миннән?
Анадан туганнан бирле
Ни рәхәт күрдем синнән?

Шулай, авыл белән елашып саубуллаштык. Тик безне укырга

алмадылар. Аннары мин өйгә кайтып киттем. Ә Миргазиз эретеп ябыштыручы (сварщик) һөнәрен үзләштерергә калды", – дип исенә төшерә.

Шулай итеп, Миргазиз Новокуйбышевскида эшли башлый. Ә озак та үтми, сөйгәненең Үзбәкстандагы апасы янына киткәнен ишетә. Егетнең эченә пошаман төшә, аны югалтудан курка башлый ул. Һәм, бөтен нәрсәне ташлап, Үзбәкстанга китә.

Ул турыда Әклимә ханым: "Апамның мине җибәрәсе килми, ә Миргазизем ашкына. Тизрәк уртак тормыш корасы килде аның. Ничек итеп каршы килим инде, ризалаштым. Аңа иярдем дә киттем. Авылга кайтып, матур гына туй уйнадык. Аннары кабат Үзбәкстанның Каттакурган шәһәренә киттек. Улыбыз Равил анда туды", – дип сөйләгән иде.

Ул чакларны искә төшереп, минем инәкәй дә: "Җәүдәтнең туенда әрчиләрне (кәләш туганнары) алар йөртте. Шәһәрдән кайттылар. Әклимә сапогилар кигән – шулкадәр матур инде! Икесе дә чибәр, затлы итеп киенгәннәр, карап кына торырлык инде менә. Миргазиз моңлы итеп җырлый иде. Бик матур пар иде алар!" – дип сөйли.

Шулай итеп, сокланып туймаслык гаилә барлыкка килгән. Шәһәрдә яхшы гына яши башлаганнар. Тик авыл бырыбер үзенә тарткан.

"Шәһәрдә ничә ел йөрсәң дә, җыйган малың бер чемоданга гына сыя, авылга кайтыйк, өй салырбыз", – дип киңәшкәннәр дә Галигә кайтып төпләнгәннәр. Әсма апаның йортында зур өй төзегәннәр. Биредә кызлары Рузалия һәм уллары Рамил туган.

Әллә күз тигән, әллә тормыш үзе көнләшкән. Миргазиз абый кинәттән генә чирли башлаган. Бик нык сызланган ул. Үлем түшәгендә ятуына карамастан, Әклимә апага, туганнарына яхшы киңәшләр биргән, изге үгет-нәсыйхәтләрен җиткергән.

Шулай бервакыт Рәйсә апа ире Иршат белән хәл белергә барганнар. Иршат абыйның әзрәк салгалый торган чагы икән. Миргазиз абый сызлануы басылган арада: "И, бажа, мин сиңа бер сүз әйтим әле. Зинһар, гаиләңнең кадерен бел. Менә мин исән булсам, шушы өйләрне, бөтен дөньяны калдырып чыгып кит, дисәләр, берәр палагы (зур брезент җәймә, элгәре аның белән ашлыкларны каплаганнар) ябынып, балаларымны да Әклимәмне генә алып, берсүзсез чыгып китәр идем! Гаиләң бар бит, бажа, балаларың бар!" – дигән.

Берсеннән-берсе бәләкәй өч сабыен һәм Әклимәсен калдырып китеп барган ул.

Шул көннән иренең: "Син – көчле хатын, Аллаһы теләсә, кызыбыз белән улларыбызны үстерә алачаксың, мин сиңа ышанам", – дигән сүзләрен алга куеп, бөтен тормышын балаларына багышлаган Әклимә ханым.

"Аларны үстергәндә кыенлыклар күп булды инде. Хәзер бу турыда искә дә төшерәсе килми, – дип уртаклашкан иде Әклимә апа. – Алай да, бер вакыйга турында сөйләп үтәсе килә. Көзге як. Тавыкларыма алачык ясарга кирәк иде. Арлы-бирле йөреп, киртәләр, ике багана таптым. Ә күршедә сарай салалар. Берничә ир-ат шуның түбәсен яба. "Ике баганамны гына утыртып бирегез әле," – дип сорадым. Утыртып бирәм дигән идем, алар миңа: "Багана утыртучы кирәккәч, кияүгә чыгарга", – дип көлделәр. И гарьләнгән идем шунда, и елаган идем.

Шулай яшәдем, иркәм, сер бирмәдем, Аллаһыга шөкер. Үз гомеремдә бер генә ир-атның да миңа бармак тидергәне булмады, әлхәмдүлилләһ! Балаларымның йөзләренә тап төшермәдем, күзләренә яшь китермәдем. Ә тавыкларыма алачыкны Гайнафа абыстай белән ясадык.

Шулай тормыш көттек инде. Ындыр тутырып суган, бәрәңге чәчә идек. Шәл бәйлибез. Арада кәсепкә дә йөрдем. Кышын көнбагыш сатарга китәм. Берничә көн йөреп, бераз акчасын булдырып, балаларыма кирәк-яраклар алып кайтам. Өйдән чыгып киткәч, күңел тыныч түгел инде, билгеле, кызым белән улларым ни эшлиләр икән, тамаклары тукмы, өй җылымы дип борчыласың.

Өйгә кайтып керәм – мич ягылган, балаларым сәкедә тезелеп йоклап яталар. Рузалиям мич янында ук, уртада Рамилем, ә кырыйда Равилем. Сеңелесе белән энесен җылырак якка яткырган инде олы улым. Иртәнгә таба өй суына бит. Утыны да чамалы гына.

Мин балаларыма карата бик таләпчән булдым. Үзләренә эшне бүлеп куям – мин кайтуга үтәлгән булырга тиеш. Һәм, әлхәмдүлил-



*Әклимә апа балалары, оныклары, туруннары арасында*

ләһ, шулай булды да. Ындырларым ялт итеп тора иде, суган да, чәмчүк тә чәчтек. Балалар тырышты, эш бетмичә, урамга чыгу юк. Бер-берсен үзләре үк контрольдә тоталар иде алар. Бөтен эшнең рәтен белеп үстеләр".

Әклимә ападан балалары турында сорашкач, аның йөзе тагын да яктырып китә. Исемнәрен дә Рузалиям, Равилем, Рамилем, дип иркәләп кенә әйтә иде.

Менә ул горурланып олы улы турында сөйли: "Равилем буй-сыны белән дә, бите белән дә Миргазиземә охшаган. Тырыш, уңган, җизнәсе белән бергә эшлиләр, аңардан бер дә калышмый. Ирем үләр алдыннан мине юатып: "Равилебез акыллы, төпле малай, ярдәм итәр, Аллаһы теләсә!" – дигән иде. Ул вакытта аңа алты яшь кенә иде бит ләбаса. Нәкъ шулай булып чыкты да! Ирем алдан күрә белгән. Равилем кечкенәдән җаваплылыкны үз өстенә ала иде. Мин җигелеп тормыш йөген тарттым, ә ул йорт-җирләрне, өйне, малларны карады. Иркәләренең дәресләрен карата, ашата-эчертә, бар дөньяны тәртиптә тота иде. Равилем хәзерге тормышын да шулай ук акыл, тәртип белән алып бара. Тапкан малының кадерен белә, тиешле өлешен туганнарына, миңа, динебез үсешенә бүлеп бирә.

Шатланып туя алмыйм, Раббым аңа акыллы хатын бүләк итте. Киленем Динәм – Равилнең уң кулы, сердәше-киңәштәше, оныкларыма – назлы әни. Ипле, игелекле бала".

Алар турында күршедә генә яшәгән Халидә абыстай да: "Шулхәтле әйбәтләр, әниләрен хөрмәт итәләр, аны рәнҗетүдән бик куркалар. Аллаһыдан сорый белгән шул Әклимә!" – дип әйтә торган иде.

Динә ханым, чыннан да, итагатьле, уңган хатын-кыз.Өй кыриендагы бакчасында ниләр генә үсми: кыяр-помидордан алып, зифа буйлы туяларга кадәр.

Динә ханымнан ниндидер иләһи җылылык бөркеп тора. Үзе белән әз генә сөйләшеп алсаң да, күңелгә бик рәхәт булып китә. Равил белән бер-берсенә бик туры килгәннәр алар! Балалары – Рифат белән Дания дә тәүфыйклылар, үз тормышлары белән яшиләр, тырышып эшлиләр. Ә Равил белән Динә, бар назларын оныкларына биреп, сөенеп гомер итәләр.

Балаларының һәрбересе турында сәгатьләр буе сөйләргә дә риза иде Әклимә апа:

"Рузалиям, балакаем, йөрәк маем! Ул минем сердәшем дә, киңәшчем дә. Минеке генә түгел, бертуганнары өчен дә шулай ул".

Рузалия ханым, дөрестән дә, бу гаиләнең йөзек кашыдыр, мөгаен. "Самар татарлары" журналында Гөлнур Айзатның бер шигыренә тап булган идем. Аны укуга, Рузалия ханым күз алдына килеп басты. Шагыйрә әйтерсең лә аның турында язган инде менә:

Һәр бөек ир-ат артында
Акыллы хатын тора.
Дөрес түгелме бу сүзем?
Теләсә кемнән сора!
Һәр бөек ир-ат артында
Бик сабыр хатын яши.
Җүләрләр генә күп сөйли,
Акыллы кеше дәшми...
Һәр бөек ир-ат артында
Тырыш хатын көн күрә,
Аның тырышлыгы аша
Ирләре була түрә.
Һәр бөек ир-ат артында
Хатынның моңлысы бар.
Ул моңнарда – тормыш үзе,
Аны да тыңлыйсы бар!
Һәр бөек ир-ат артында
Зыялы хатын була.
Зыялы булса хатыны,
Ирләрнең эше уңа!
Һәр бөек ир-ат артында
Бик серле хатын гына...
Гаиләне алып бара,
Сөйләми артыгын да...
Һәр бөек ир-ат артында
Кем тора? Уйлап кара!

Рузалия – нәкъ шундый акыллы, сабыр, тырыш һәм затлы ханым.

"Киявем дә бик әйбәт кеше булды. Кызымның кадерен белә, мине дә бик якын күрә. Акыллы, тормышын динебез белән тигез алып бара", – дигән иде Әклимә апа.

Аның бу сүзләренә минем дә дәлилем бар. 2002 елда Похвистнево хастаханәсендә операция ясаттым. Шунда ятканда Марий-Эл кызы Валентина, минем Гали авылыныкы икәнне белгәч: "А у меня начальник Алькинский, Мударис Музагитович Латыпов, очень хороший человек", – дигән иде. Аннары үзенең ничек Похвистневога килеп эләккәне, биредә эшкә урнашуы, Мөдәррис әфәндenең аңа булышуы турында сөйләде. Палатадагы хатыннар да, аңа кушылып, Әклимә апа киявенең яхшылыкларын тезеп киттеләр. Белсәгез икән, нинди горурлык хисләре кичердем мин шунда! Ул бит Гали авылыннан, безнеке!

Шулай итеп, ике яхшы кеше – Мөдәррис белән Рузалия кавышканнар да изгелекләр кылып



*Әклимә апа, Әнисә, Халидә ханымнар*

гомер итәләр. Мәчетләр салуга да, башка игелекле гамәлләргә дә үз өлешләрен кертәләр.

Әлхәмдүлилләһ, Мөдәррис белән Рузалия дин кушканча яшиләр. Аларның балалары да тәртипле, эшле-тормышлы. Әти-әнисе сызган юлдан матур итеп алга атлыйлар. Барысы да Аллаһы ризалыгы өчен мөселман кешесенә тиеш булган барлык гамәлләрне үтиләр.

Ә кече улы Рамил турында түбәндәгеләрне сөйләгән иде Әклимә ханым:

“Әтисе чирләгәндә аңа сигез ай гына иде әле. Миргәзиземә приступ була башлый да, Рамилем еларга тотына, берничек тә туктатып булмый үзен. Әтисенең приступы бетә – ул да елаудан туктый. Аптырап бетә идек.

“Шул балага сүз әйтә күрмәгез! Минем хәлемне тоеп тора бит, изге бала ул!” – дия иде Миргазизем”.

Рамил, чыннан да, йомшак күңелле булып үсеп житкән. “Әнием кебек кыз тапкач кына өйләнәм”, – дип әйткән ул яшь чагында. Анасын шулкадәр яраткан, хөрмәт иткән ки, аңа охшаган кыз эзләгән. Иптәшләре белән аралашканда да, берәр нинди проблема килеп чыкса: “Кайтып, инәкәй белән киңәшәм әле”, – дия торган булган.

Рамилдәге Әклимә апа тәрбиясенең җимеше булган сыйфатларны – миһербанлык, шәфкатьлелек, иплелекне авылыбыз халкы һәрдаим тоеп яши. Аның кабер казу өчен җайланылган махсус техникасы белән кулланып торабыз. Без аңа бик рәхмәтле.

Ә Рамиле, авариягә эләгеп, хастаханәдә яткан чактагы кичерешләре турында Әклимә апа: “Үземне кая куярга белмәдем, тәрәзәдән күземне дә алмадым. Намазлыктан торам да тәрәзә янына юнәләм: кем килер, ни әйтер? Аллаһымнан бик нык сорадым. Әлхәмдүлилләһ, ярдәменнән калдырмады”, – дип елый-елый сөйләгән иде. Бу хәлләрне хәтта искә алуы да кыен иде аңа.

Рамил – тормышның асылын аңлаган, белдекле һәм ярдәмчел ир-ат. Үзенә лаеклы тормыш иптәше дә сайлаган ул. Хатыны Миләүшә – мактаулы килен дә,



*Әклимә апа оныгы Ислам белән*

ышанычлы хатын да, кайгыртучан әни дә.

Аллаһы Тәгалә биргән сынауларны да сабырлык белән үткәрделәр алар. Миләүшәнең әнисе – Әнисә апа чирләгәч, бармаган табиблары, йөрмәгән юллары калмады. Рамил авариягә эләккәч тә, аңа ярдәмгә бөтен туганнары белән күтәрелделәр. Шундый миһербанлы, шәфкатьле, бердәм һәм туган җанлы алар.

Рузалия дә: “Миләүшә инәкәйне җылы аштан өзмәде. Аллаһының рәхмәтләре яусын! Үзе дә балалары өчен кадерле әни булсын!” – ди.

Миләүшә, дини гыйлем алып, бүгенге көндә абыстай дәрәҗәсенә ирешә.

Малайлары Ислам, Илһам, Йосыф һәм кызлары Замирә – аларның тормышы мәгънәсе, ә оныклары – яме, бизәге. Бәхетле генә булсыннар!

“Оясында ни күрсә – очканында шул була” ди бит халык мәкале. Бу гаилә – шушы мәкальгә бер мисал. Равил, Рузалия, Рамил, әниләренең: “Бәбкәйләрем, тату булыгыз!” – дигән васыятен үтәп, бер-берсен кайгыртып, ярдәмләшеп гомер итәләр. Туганлык хисләре аларга балачактан ныклап сеңеп калган.

Барысы да тәүфыйклы, дин таләпләренә буйсынып, игелекләр кылып яшиләр. Аларның үрнәгендә үскән уллары, кызлары, оныклары да бары тик мактау сүзләренә генә лаек.

Балалары да Әклимә апаны кадер-хөрмәттә яшәттеләр, соңгы көненә хәтле янында булдылар, аның өчен өзелеп тордылар. Җомга саен төп йортка, газиз инәкәйләре янына җыелалар, рәхәтләнеп сөйләшәләр, киңәшәләр, шатланалар иде. Бер-берсеннән яктылык, җылылык алып китәләр дә тирә-юньдәге кешеләргә өләшәләр. Нинди матур гадәт бит бу, күпләргә үрнәк!

Үзе туры юлдан барган, тырыш, миһербанлы булган кеше генә тәртипле, игелекле балалар тәрбияли ала шул. Әклимә апа – үз максатына ирешкән бәхетле Ана. Аның тормышы һәрберебезгә үрнәккә куярлык! Үткән юлы сикәлтәле, әмма якты. Яшәгән гомере мәгънәле, изгелекләр белән сугарылган.

Әклимә апа Мостафинаның урыны җәннәт түрләрендә булсын, кылган догаларыбыз аның рухын шатландырсын!

# Мидхәт Әминов. Гармунга мәңгегә гашыйк кеше

***2026 елда Самарның «Идел» эстрада ансамбленә 30 ел тула, ә 20 гыйнварда әлеге төркемнең җитәкчесе, гармунчы-виртуоз, «Заман» татар фольклор балалар ансамбле гармунчысы, өлкә һәм күрше төбәкләр тамашачыларының яраткан артисты Мидхәт Әминов 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә!***

*Эльмира Сәйфуллина*



Ләкин саннар документта гына. Бу һәрвакытта да көр һәм күтәренке күңелле ир-атка карап, аңа беркем дә үз яшен бирмәс иде. Мидхәт абыйның энергиясе үзенә дә, тормыш дулкыннарын җиңеп, алга атларга, позитивлыгы белән башкаларны "зарарларга" да җитә. Нинди генә урында булмасын, ул шунда ук публиканың бөтен игътибарын җәлеп итә. Бәлки, аның шушы сыйфатлары менә инде 30 ел дәвамында "Идел" халык ансамблен җитәкләргә булышадыр да.

30 ел гомер... Азмы әллә күпме? Үзешчән артистларны берләштергән иҗади коллектив өчен – бу бик озын юл, минемчә.

Самарның «Идел» татар халык эстрада ансамблен өлкәдә яшәүчеләр дә, күрше төбәкләр дә бик яхшы белә һәм ярата.

Коллективка нигез салучы һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе Мидхәт Әминов ансамбль оештырырга карар кылган вакытта бу проект шулкадәр озын гомерле булыр дип уйладымы икән? Энергиясе ташып торган үзенчәлекле музыкант һәрвакытта да үз тирәсендә талантлы, тырыш һәм татар көйләрен, татар моңын яратучыларны туплый белгән. Еллар аккан судай узган саен ансамбльнең составы да үзгәреп торган. Әмма коллективта 30 ел дәвамында Мидхәт абый белән бергә утны да, суны да кичкән артистлар бар. Сүз ансамбльнең профессиональ музыканты Лилия һәм сандугачтай моңлы солисткасы Миләүшә Хәлимуллиналар турында...

Элек бераз «Идел»нең тарихы белән танышып китү урынлы булыр дип уйлыйм.

Кошки районының Иске Җүрәй авылы егете Мидхәт Әминов 1976 елда елга техникумына укырга



керү теләге белән Куйбышевка килә. Әмма төрле сәбәпләр аркасында аның хыялы чынга ашмый. Шулай да, күпчелек авыл кешеләре кебек үк, егет аптырап калмый, кабель җитештерүче завод каршында эшләп килгән училищега керә. Тулай торакта бүлмә бирәләр, көненә өч тапкыр ашаталар, стипендия түлиләр – барысы да әйбәт. Әмма Мидхәтнең күңеленә нидер җитми. Ә төгәлрәк – балачактан җыр-моңга гашыйк булган талантлы егеткә татар мохиты, татар көе, тальян моңы җитми.

Шуны сизгәндәй, 1977 елда Мидхәтнең балачак күршесе Сания Нуретдинова аны «Ялкынлы яшьлек» ансамбленә чакыра. Мидхәтне анда биюче итеп алалар. Җиңел сөякле авыл егете үз талантын бик тиз таныта һәм 20 ел дәвамында бию труппасының солисты булып тора. Ул башкарган легендар «Муса Җәлил» ролен тамашачылар әле дә сагынып искә алалар.

– Миңа шундый әһәмиятле рольләр ышандырганы, профессиональ нечкәлекләргә өйрәткәне өчен Альберт Закирович Гаязовка бик рәхмәтлемен, – дип сөйли бүген дә Мидхәт абый.

«Ялкынлы яшьлек» ансамблендә Мидхәт әфәнде танылган якташыбыз, виртуоз гармунчы, музыкант Рөстәм Вәлиев белән таныша. Ул елларда әле Рөстәм гади, әмма бик талантлы һәвәскәр артист буларак кына билгеле булган. Менә шушы танышу Мидхәт Әминовта музыка коралларына мәхәббәт уята, биюче егетне бүген без белгән уникаль музыкант итә.

– Рөстәмнең җирле оста (Киселев) ясаган гармуны бар иде. Аның шушы гармунда уйнаганын ишеткәч, бу инструментка мәңгегә гашыйк булдым, үземә дә шундый гармун алу хыялы белән яндым. Әмма авыр заманалар булганлыктан, хыялым 1995–1996 елларда Хәбил һәм Илшат Бикташевлар ярдәмендә генә чынга ашты. Моның өчен бу кешеләргә рәхмәтләрем чиксез. Әлеге гармун бүгенге көндә дә минем иң якын дустым булып кала. Аның моңы бернинди гармун тавышына да охшамаган, ул үзенә бертөрле, аерым, сихри, кыскасы – искиткеч, – дип елмая артист.

Озын сүзнең кыскасы, артист үсә, күпкырлы талант иясенә 20 елдан артык бер юнәлештә генә





атлауның кызыгы калмый. Нәкъ шул вакытта Мидхәт Әминовның күңелендә үз коллективын җыю, ансамбль булдыру теләге туа. Ачык йөзле, аралашучан артистның күпсанлы танышлары арасында профессиональ оркестрда уйнаучы саксофончы Али Губанов та була. Ул Мидхәтнең идеясен хуплый, һәм 1996 елда «Идел» ансамбле барлыкка килә. Аның иң беренче составында Самарның талантлы һәвәскәр артистлары – Галия Мостафина, Раилә Сибгәтуллина, Али Губанов, Искәндәр Әхмәтов булган. Ә җитәкчесе булып беренче көннән бүгенгә кадәр Мидхәт Әминов тора. Соңрак коллективка Ринат



һәм Халидә Вәлиевлар, Гөлназ Баһаутдинова, Рәфгать Фәретдинов кушылалар.

– Ансамбльнең беренче гастрольләре гел өлкә авыллары буйлап узды. Музыкантыбыз Али Губановның төп эш урыны белән ансамбль тормышын параллель рәвештә алып баруы кыенлаша башлады, безгә тиз арада тагын бер музыкант табарга кирәк иде, – дип искә ала Мидхәт абый.

Эзләнә, сөйләшә торгач, татарча сарафан радиосы бик тиз нәтиҗә бирә. Альмирә Мингачева (автор искәрмәсе: бүген без аны хоккейчы Таһир Мингачевның әнисе буларак беләбез) училищеда музыка бүлегендә укучы дусты Лилия Абдуллинаны тәкъдим итә. Мидхәт абый шәһәр читенә, 116нчы километр бистәсенә талантлы пианистканы эзләп бара. Билгеле инде, татарлар иң элек җитәкчене чәй табыны янына чакыралар, аннары сүз Лилия турында була. Кызның таланты һәм синтезаторда уйный белүе аңа бик ошый, әмма артистканың







бары тик 15 яшендә булуы бераз куркыта. Шулай да, Мидхәт абый Лилияне ансамбльгә ала һәм һәр репетициягә аны үзе барып алып, үзе өенә илтеп куя башлый.

– Балачагым татар җырларына, гармун көенә төренеп үтте. Әнием Рәзинә һәм әтием Бәгъзәр икесе дә матур җырлыйлар, әтием баянда да уйный. Шуңа күрә музыкага омтылышымны алар бик хупладылар, миңа профессиональ музыкаль белем бирергә тырыштылар. Башта - музыка мәктәбен, аннары - педагогика училищесының музыка бүлеген, аннан соң сәнгать академиясенең эстрада бүлеген тәмамладым. Ә балачак хыялым – синтезаторны миңа әнием Гарәпстанга командировкага баргач алып кайткан иде, – дип сөйли Лилия. – Мидхәт абый белән танышкан вакытта зур сәхнәдә чыгыш ясау турында уйлап та, күзаллап та караганым юк иде. «Идел» ансамбленә ничек курыкмыйча килеп кушылганымны, миңа кадәр ничәмә еллар зур сәхнәләрдә җырлап йөргән артистлар өчен аккомпаниатор булырга ризалашканымны сизми дә калдым. Равил белән Альмирә Мингачевларга миңа сәхнә тормышын бүләк иткәннәре өчен бүген дә рәхмәтләмен.

Озак та үтми, Мидхәт абый Рәфгать Фәретдинов киңәше буенча искиткеч моңлы, матур тавышлы җырчы – Шенталы районының Татар Әбдекие кызы Миләүшә Минебаева белән таныша һәм аны «Идел»гә чакыра.

– Мин үземне белгәннән бирле сәхнәдә, – дип башлады сүзен Миләүшә. – Әтием Минәхтәм дә, әнием Дания дә – җыр-моңга гашыйк кешеләр, аларның бөтен күңелләре сәхнәгә, иҗатка бәйле иде. Әнием бик матур җырлый иде, клубта – сәнгать җитәкчесе, ә әтием – оста баянчы, 40 елдан артык, соңгы сулышына кадәр диярлек авыл клубында эшләде. «Идел» беренче гастрольләре белән безнең авылга килгән вакытта мин, үсмер кыз, кайчан да булса бу коллектив белән бер сәхнәдә чыгыш ясармын дип уйларга да батырчылык итмәдем. Әтиемнең: «Минем кызымны да үзегезгә алыгыз», – дип шаяртканы хәзер дә исемдә. Ә тиздән Мидхәт абый мине чыннан да ансамбльгә чакырыр дип уйламадык та. «Идел» артисты булуы ул чакта минем өчен беркайчан да чынга ашмаслык хыял иде.

– Әйе, дөрестән дә шулай, – дип сүзгә кушылды Мидхәт абый. – Әбдекидәге без кунакта булган йорт булачак җырчыбызның туган йорты икәнен кем уйлый бит. Безне якын туганнарыдай каршы алган Минәхтәм абый белән Дания апаның шундый талантлы бала үстергәннәрен дә, Миләүшәнең җырлавын да ул безнең ансамбльгә килгәч кенә ишеттем. Аның беркемнекенә дә охшамаган тембры, бәрхеттәй, зәвыклы тавышы беренче ноталарыннан ук гашыйк итә. Бу талант аңа



эти-әнисеннән күчкән булса кирәк. Мин аларга безгә шундый артист үстереп биргәннәре, ә Рәфгатькә Миләүшәне безнең ансамбльгә китергәне өчен бик рәхмәтлемен.

– Беренче репетициянең азагында ук Миләүшә инде күптән безнең коллектив вәкиле булып тоелды, без бер-беребезне әллә кайчаннан бирле беләбез кебек иде. Миләүшәнең безнең коллективка килүенә барысыннан да ныграк мин шатланганмындыр, мөгаен. Чөнки калган артистлар миннән күпкә олы иде, ә Миләүшә белән без икебез дә бер яшьтә, бик тиз дуслашып киттек. Бераздан туганлыштык та – килендәшләр булып куйдык, – дип елмая Лилия Хәлимуллина (Абдуллина). – Гастрольләргә барыр өчен һәрвакыт автобус ялларга кирәк иде. Шулай, бер сәфәребезгә Оренбург өлкәсенең Әсәкәй районы егете Ринат Хәлимуллин йөрткән машинага утырып барырга туры килде. Менә шунда алар Миләүшә белән танышып киттеләр, очраша башладылар. Бераздан мине Ринатның игезәк туганы Марат белән таныштырдылар.



Шулай итеп, дус кызлар, игезәк егетләргә кияүгә чыгып, килендәшләр булып китәләр, һәм икесе дә бер фамилия йөртә башлыйлар. Миләүшәнең беренче баласы Салават туа, озак та үтми, Лилиянең Эльвинасы дөньяга аваз сала.

– Алар декрет ялына да тукталмадылар диярлек, – дип сөйли Мидхәт абый. – Биләүгә төргән сабыйларын үзләре белән репетицияләргә алып йөрделәр, ә балалар шундый көчле тавыш астында да урындыкта яки эскәмиядә рәхәтләнеп йоклыйлар иде.

– Шуңа күрә алар, бераз тәпи йөреп, сөйләшә башлауга, сәхнәгә тартылдылар һәм бүгенге көндә



дә сәхнәсез бер көн дә яши алмыйлар, – дип көлешәләр Хәлимуллиналар.

Эльвина Хәлимуллина Самар тамашачыларына – талантлы саксофончы, ә аның икетуганы Салават Хәлимуллин җырчы буларак танышлар. Алар дуэт булып та бик матур һәм дәртле җырлар башкаралар. Өлкәннәр белән беррәттән милли мәдәниятебезне саклау юлында күп көч куялар һәм аңа яңа, заманча агым кертәләр.

Эльвина Хәлимуллина да, энисе кебек, музыкаль белем алган. Сеңелесе Алсу да саксофонда уйный икән, энисе белән апасы юлын сайлаган ул.

Салават, балачактан җырлап-биеп үссә дә, музыкаль белем алырга омтылмаган. «Яктылык» мәктәбен тәмамлагач, армиядә хезмәт итәргә һәм югары белем алырга планлаштыра егет. Әмма соңгы бер ел эчендә аның планнары кискен үзгәрә, һәм ул үзен тулысынча иҗатка багышларга карар кыла. Хәрби хезмәт үткәндә вакытын бушка уздырмый, вокал осталыгы өстендә эшли, аранжировка серләрен өйрәнә башлый һәм акрынлап үзе күптән язган җырларын сәхнәгә чыгарлык итеп шомарта. Салават Эльвина укыган Шаталов исемендәге училищеда музыка режиссеры бүлеген тәмамлый. Әлеге һөнәр серләренә үзлегеннән генә өйрәнеп тә зур уңышларга ирешкән егет, махсус белем алып чыккач, тамашачыларны тагын да сыйфатлырак иҗат җимешләре белән сөендерә. Аның энесе Илназ да бик матур җырлый. Малайның тавышы Минәхтәм бабасының тавышына охшаган, диләр.



Ни чәчсәң – шуны урырсың, дип дөрес әйткәннәр икән. Хәлимуллиннар гаиләсе бу әйтемне раслый. Гомерләренең күп өлешен иҗатка, милли мәдәниятебезне саклап, аны яшь буынга тапшыруга багышлаган Лилия һәм Миләүшә Хәлимуллиналар – зур хөрмәткә лаеклы, күпләребезгә үрнәк булырлык аналар. Тормыш иптәшләре Ринат белән Маратка да, хатыннарының шөгыльләрен хуплап, аларга терәк һәм ярдәмче булулары, сабырлыклары өчен бик зур рәхмәт.

Ансамбльнең җитәкчесе – “Гали гармуннары”, “Җирнең бәллүр йөрәге” фестивальләре лауреаты Мидхәт Әминов та Хәлимулиннар гаиләсенә рәхмәтле.

- 30 елга якын гомер эчендә төрле хәлләр булды. Лилия белән Миләүшәгә мин үземә ышангандай ышанам. Олырак булсам да, алардан күп нәрсәгә өйрәндем. Сәхнәдә дә без бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Ансамбльгә чагыштырмача күптән түгел килеп кушылган яшь артистларыбыз – Илдар Хәкимҗанов, Алсинә Дәүләтбаева да, Айгөл Минастинова, Мансур Сафин һәм Айгөл Вәлиуллова да бер-берсен һәм безне күптән беләләр иде сыман. Коллективка бик тиз ияләштеләр. Гомумән, ансамблебез кешеләре бер гаиләдәй тату, Аллаһыга шөкер. Алар белән утка да, суга да керергә әзер мин, – дип тәмамлады сүзен җитәкче.

Юбилярларны котлап, ихлас күңелдән иң изге теләкләребезне җиткерәбез! Ансамбльгә дә, аның алыштыргысыз җитәкчесе Мидхәт Әминовка да иҗади уңышлар, рәхмәтле тамашачылар һәм озын, бәхетле гомер телибез! Сүз уңаеннан, декабрь аенда Мидхәт абыйның күпсанлы югары дәрәҗәле дипломнары, Рәхмәт хатлары исемлегенә “2025 ел ир-аты” иҗтимагый премиясе дә өстәлде. Афәрин! Лаеклы!

# “Яшьләргә тәүфыйк-һидәят сорыйм”

***Татар әбиләре бигрәк сөйкемле дә инде! Матур яулыгын бәйләп куйган, озын күлмәген кигән бу ханымнарның нурлы күзләре, ачык йөзе, тәмле сүзе, тыйнак елмаюы һәркемне үзенә җәлеп итә алырлык.***

***Миләүшә Газимова***

Менә Елховка районының Тупли авылында яшәүче 78 яшьлек Зәйтүнә әби дә нәкъ шундый. Йомшак тавышлы, ягымлы, тыйнак холыклы, сабыр бу ханым үзенә әсир итүче бер җылылык бөркеп тора. Аның акыллы, зыялы булуы сокландыра.

Әңгәмәбезне аның балачак, яшьлек елларыннан башладык.

Тупли авылында туып-үскән Зәйтүнә Минегали кызы Хөснуллинаның кечкенә чаклары бик авыр үткән.

“Мин сигезенче сыйныфны тәмамлаган гына идем, озак вакыт авырган әнием Галия 58 яшендә якты дөнья белән хушлашты. Этием дә чирле иде. 19 яшем тулгач, ул да вафат булды, - дип сөйләп китте Зәйтүнә апа. – Әни үлгәч, әтиебез безне берүзе тәрбияләде. Әби-бабайларым юк иде, алар әле ачлык елларында бакыйлыкка күчкәннәр.

Без биш бала үстек. Ә барлыгы унөч булган, калганнары тиф авыруыннан үлгәннәр.

Гаиләдә мин иң кечесе. Апаларым кияүгә киткәч, әтием белән икәү генә калдык.

Эшләп үстем мин. Сыер саварга, ризык пешерергә, икмәк салырга, бәрәңгесен чәчәргә, утарга, бәбкәләрне үстерергә – авылда эш бетмәслек бит инде ул. Әтине дә ашатып, карап торырга кирәк.

Буем җитмәгәч, урындыкка басып, камыр җәя, казанда аш пешерә идем.

Ризык, киенү ягы да начар бит инде. Армиягә киткәнче абыем бер ел буе әти белән әни янында эшләде. Өчесенә бергә 4 капчык арыш биргәннәр иде шунда. Шуңа яшәп кара менә!

Ачлык елларында әти-әнием, Донбасска барып, шахтада да эшләгән булганнар.

Әтием авылда тегермәнче иде. Бик башлы, акыллы кеше. Бернинди сызымсыз (чертеж) Березовка, Тупли, Яңа Буян авылларында, Елховкада тегермәннәр салган ул! Әнием башта колхозда бозаулар карады, аннары әти белән бергә тегермәндә көч куйды.

Сигез сыйныфны бетергәч, беркайда да укый алмадым мин. Колхозда төрле эш башкардым. Ә 19 яшемдә кияүгә чыккач, тормыш иптәшем белән Олы Черниговкага күчеп киттек. Анда өч балабыз



туды: Нәбиулла, Халидә, Зөлфия. Тик ирдән уңмадым шул, 13 ел яшәгәч, аңардан аерылырга туры килде”.

Нужалы балачак кичергән Зәйтүнә апага үз тормышында әле

күп авырлыклар, кайгы-хәсрәтләр күрергә туры килә. Икенчегә кияүгә чыккач, алты елдан соң хәләл җефете вафат була. Өч баласын калдырып, кызы Халидә якты дөнья белән хушлаша. Ә үзенең коронавирус белән чирләгәндә үпкәләре 95 процентка зарарланган була!

Олы Черниговкада Зәйтүнә ханым сыер савучы, икмәк пешерүче, кондитер булып эшләгән. Анда 40 ел гомер кичергәннән соң туган авылы - Туплигә әйләнеп кайткан.

Сәламәтлеге инде шактый какшап, ике таякка таянып йөрсә дә, ашарына да үзе пешерә, бакчасында яшелчәләр дә чәчә һәм әле төрле кул эшләре белән дә шөгыльләнә.

Аеруча чигүне ярата икән ул. Аның чигешләр белән тулган өе әкияттәге бер өйне хәтерләтә. Диварларында кошлар, җиләкләр, төрледән-төрле чәчәкләр сурәтләнгән паннолар күз явын алырлык, чиккән тышлы мендәрләре - үзенә бер искиткеч күренеш. Ул кульяулыклары, ул алъяпкычлары. Зәйтүнә апаның osталыгына исләрең китәр!

Үзенә заказлар да күп бирәләр икән. Авыл клубына - паннолар, Сабан туена чиккән сөлгеләр кирәксә дә, аңа мөрәҗәгать итәләр. Шулай ук ул чигешләрен авылдашларына, туганнарына бүләк итә. Бертуганнарының балалары аларны Ленинградка, Эстониягә кадәр алып киткәннәр.

"Чигү чигәргә безне әле мәктәптә укыганда өйрәткәннәр иде. Аннары моның белән чын-чынлап мавыгып киттем. Үзем генә яшәгәч, башка күңелсез уйлар керә бит ул. Чигү, бәйләм алардан арынып торырга булыша, җанымны тынычландыра", - ди әңгәмәдәшем.

Зәйтүнә апа махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итүгә дә үз өлешен кертә бит әле! Ул бер тапкыр солдатларга оекбашлар бәйләгән булган инде. Хәзер дә менә аларга чиккән кульяулыклар, 13 пар оекбаш биреп җибәргән.

"Былтыр күп бәйли алмадым шул, йоным аз иде. Ә быел авылдашым Мәрьям бер капчык йон кертте, Аллаһының рәхмәте яусын үзенә. Шушы оекбашлар ир-егетләребезнең аякларын гына түгел, күңелләрен дә җылытсын иде. Алар өчен йөрәк әрни бит", - ди язмам герое.



Зәйтүнә ханымның өе матурдан-матур чигешләрдән генә түгел, изге догалардан да нурланып тора. Менә инде 50 яшеннән алып, биш вакыт намазын, уразасын калдырмый ул.

Әти-әнисе бик дини, бу яктан гыйлемле булганнар. Балаларына кечкенәдән ислам нигезләрен өйрәткәннәр. Алар инде балачактан ураза тота торган булганнар.

Зәйтүнә апа әтисеннән тирән дини белем алып калган. Олы Черниговкада яшәгәндә остабикә булып, ларак мәҗлесләрдә укып йөргән ул.

Авыр тормыш юлын үтсә дә, милләттәшебез үзен бәхетле кеше дип саный, чөнки аның балалары акыллы, тәүфыйклы кешеләр булып җитлеккәннәр. Әниләрен кадер-хөрмәттә яшәтәләр, ярдәмнәреннән ташламыйлар. Зәйтүнә апа – бай әби бит әле. Аның 7 оныгы һәм 11 туруны (правнук) бар! Иң зур туруны инде институтта укыса, иң кечесенә әле бер яшь кенә тулган.

"Эшләп, тырышып, мал табып, өч баламны берүземә тәрбияләргә туры килде. Раббыма рәхмәтлемен - лаеклы кешеләр булып үстеләр алар. Мин үзләреннән бик канәгать, карыйлар, ярдәм итәләр. Икесе дә Олы Черниговкада яшиләр. Улым газ хуҗалыгында эшли, кызым – икмәк пешерүче.

Оныкларым да, әлхәмдүлилләһ, тәртиплеләр, шалтыратып, хәлләремне беләләр, кунакка кайталар, булышалар", - дип шатланып сөйли иң якын кешеләре турында Зәйтүнә ханым.

Балалары, оныклары ерак торгач, әлбәттә инде, аның янына алай ук еш кайтып йөри алмыйлар. Шуңа күрә Зәйтүнә апа социаль хезмәткәр ярдәменнән файдалана.

"Мине карauчы Әлфия Йосыпова кызымдай якын кешегә әйләнде. Аның миңа күрсәткән яхшылыгы, кайгыртучанлыгы, игътибарлылыгы - сүз белән генә аңлатып бирмәслек! Ире Нәҗип тә ватылган бөтен техникамны төзәтә. Машинасына утыртып, кирәк җиргә алып бара. Бик әйбәт минем авылдашларым, әлхәмдүлилләһ. Күршеләрем Равил белән Йосыф Салиховлар да гел булышалар – карымны чистартып, мичемне карап торалар.

Барысына да Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын! Исәнлектә-саулыкта, хәләл җефетләре белән тигезлектә, муллыкта яшәсеннәр, һәрьяклап бәхетле булсыннар", - дип сөйли милләттәшебез.

**"Олы һәм сикәлтәле тормыш юлы үткән, тәҗрибәле кеше буларак, яшьләргә нинди киңәшләр бирер идегез?"** - дип мөрәҗәгать иттем Зәйтүнә апага.

"Дин юлыннан атлагыз, сәдакалар бирегез, картларны зурлагыз, дияр идем. Тәмәке-хәмердән ерак торсыннар, килешле кием киеп йөрсеннәр иде.

Хәзерге тормышта яшәп була, икмәк мул, эш бар. Иренмәскә, тырышырга гына кирәк. Мал тапсыннар, үзләрен үзләре карасыннар иде.

Намаз укыган саен Раббыбыздан яшьләргә тәүфыйк-һидәят сорыйм мин".

# ИСЛАМ ДИНЕНӘ КИЛЕРГӘ БЕРКАЙЧАН ДА СОҢ ТҮГЕЛ



***Байтак еллар элек "Бердәмлек" газетасында "Ислам дине утлы күмер кебек, тотсаң - пешерер, куйсаң - сүнәр" дип аталган язма дөнья күргән иде. Ялгышмасам, аның авторы мәрхүм, хөрмәтле мөхәрриребез Рәфгать ага Әһлиуллин иде.***

***Нурсинә Хәкимова***

Мәкаләдә өлкәбезнең күренекле шәхесе – ул вакытта Региональ дини нәзарәте рәисе, мөфти булган Вагыйз хәзрәт Яруллин тормышы тасвирланган, торгынлык елларында аның ислам диненә карата мәхәббәте хакында бик авыр язмыш кичерүе турында бәян ителгән иде. Шушы язманы укыгач, ул гомерлеккә хәтер төпкелендә уелып калды.

Әлхәмдүлилләһ, хәзер илебездә дин иреге! Теләгән югары уку йортына кереп, дини гыйлем үзләштерергә, мәчеткә килеп, рәхәтләнеп намаз укырга мөмкин.

Хәзерге язмам Шенталы авылында яшәүче, өлкән яшенә җитеп, Татарстандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган Нәсимә ханым Сафина турында булыр.

Ә хәзер аның балачагына күз салыйк әле. Нәсимә апа Шенталы районындагы Карабикол авылында гомер иткән Исхак ага белән Хәдичә апа Әхмәдиевлар гаиләсендә алтынчы бала булып дөньяга килә.

Исхак абый, Бөек Ватан сугышында катнашып, Берлинга кадәр барып җиткән фронтовик буларак билгеле. Авылга әйләнеп кайткач, Хәдичә исемле бик матур кыз белән гаилә корып җибәрә ул. Башта авыл җирлеге идарәсе җитәкчесе булып эшли. Үзен яхшы яктан гына күрсәткән, тырыш Исхак Әхмәдиевны соңрак авыл хуҗалыгы рәисе итеп сайлыйлар.

Гаиләдә җиде бала дөньяга килә: Шәһит, Галия, Гайния, Рәшит, Рәсимә, Нәсимә һәм Рәфкать. Эш белән тәрбияләнеп, тормышка яраклы булып үсеп җитәләр алар.

Ә хәзер язмам героеның матур гаилә тормышы белән танышып үтик әле.

Нәсимә апаның ире – Наил Котдус улы тумышы белән безгә чиктәш Татарстанның Чирмешән районындагы Лашман авылыннан. Сафиннар гаиләсе Шенталыга күчеп килгән вакытта Наил җиткән егет була инде.

Ни генә әйтсәң дә, яшьлек - бик матур чор бит ул. Күркәм табигатьле, елмаючан, гади Нәсимәне очраткач, беренче күрешүдән үк егет киләчәк язмышын шушы кыздан башка күз алдына да китерә алмый. Нәсимә дә аңа битараф түгеллеген белдерә. Шулай итеп, дөньяда тиң сөюле мөселман гаиләсе барлыкка килә.

Сафиннар бераз Шенталыда яшәп алгач, кызлары Гүзәлияне алып, Себергә – Байкал-Амур магистраленә китеп баралар. Биредә Наил абый – Иркутск өлкәсендәге Усть-Кут шәһәрендә саклык банкының ревизия бүлегендә өлкән инспектор, ә Нәсимә апа ипи пешерүче булып эшли башлыйлар. Яшьли хезмәт белән сугарылып үскән Наил әфәнде һәм Нәсимә ханым бик тиз арада эшләрендә абруй казанып өлгерәләр. Алар күптөрле мактау грамоталарына лаек булалар. Ә Нәсимә апа "БАМ төзелешендә актив катнашкан өчен" медале белән бүләкләнә.

Тормыш туктап тормый, алга баруын дәвам итә. Озак та үтми, гаилә бәхетен тулыландырып, уллары Искәндәр дөньяга килә. Менә шулай күпмедер вакыт үтеп киткәч, Сафиннар гаиләсен борчу ала. Чөнки карт, авыру әти-әниләре турында еш кына сөйләшүләр булгалап тора. Шуңа күрә алар, балаларын ияртеп, кабат Шенталыга кайталар һәм биредә тормыш учагын тергезеп җибәрәләр.

Беркөнне Карабиколга әти-әниләренә хәл белергә баргач, Нәсимә апа алардан:

– Әткәй, әнкәй, алдагы көндә кайда торыр идегез? Авылдамы әллә шәһәрдәме? – дип сорый.

Билгеле инде, саф һавалы авыл җирендә гомер иткән өлкәннәрнең шәһәр фатирына барып утырасылары килми шул. Шуңа күрә Нәсимә ханым белән Наил әфәнде, берсүзсез риза булып, Шенталыга күченәләр.

Монда Наил Котдус улы социаль яклау үзәгендә опека һәм попечительлек бүлегендә әйдәп баручы белгеч булып эшли. Ә Нәсимә ханым башта ялгыз яшәүче әби-бабайларга хезмәт күрсәтсә, бик озак та үтми, аны бүлек җитәкчесе итеп куялар.

Байтак еллар эшләгәч, икесенә дә "Хезмәт ветераны" исеме би-

реләә, һәм шуннан алар лаеклы ялга китәләр.

Яшь чак – дәртле чак. Ләкин дөнья мәшәкатьләренә уралып, гомер үтеп киткәнен сизми дә калабыз. Кайчак адәм баласы, уйларының үзгәрүен тоеп, артына борылып карый да бөтен халәте, калебе белән ислам дине кушканча яшәргә тырыша башлый.

– Беркөнне йокыдан уянып, шушы дөньяга күз салгач, миңа нидер җитмәгәнен сиздем. Миңа дини тәрбия, белем кирәклеген аңлап алдым. Хәләл җефетем белән киңәшләшкәч, без милләттәшем Мәрьям Газизова белән рухи мәркәзебез – Казан шәһәренә юл тоттык.

"Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә барып, дини белем аласыбыз килүе турында белдергәч, хөрмәтле хәзрәт: "Нишләп болай соңга калдыгыз соң? Бераз алданрак килергә ярамадымы?" – дип сорады. "Ун ел буена өлкән яшьтәге авыру әти-әниемне карадым", – дип әйтергә мәҗбүр булдым.

Ул миңа күтәрелеп карады да берсүзсез: "Керегез, имтихан тапшырып карагыз", – диде.

Имтиханны уңышлы гына тапшыргач, безне укырга алдылар. Бик зур рәхмәт аларга!

Аллаһыга мең шөкер, без Мәрьям белән дүрт ел читтән торып белем тупладык һәм мәдрәсәне уңышлы тәмамладык. Бүгенге көндә Шенталыда вафат булучыларны мәңгелек йортка озатышам, мәҗлесләрдә Коръән укыйм. Әгәр бер-бер сәбәп белән бара алмый калсам, боларны Мәрьям Газизова үти.

Әлхәмдүлилләһ, авылыбызда мәчетебез гөрләп эшләп тора. Биредә Хәсән Сәхапов имамлык итә, ул үзенә йөкләнгән бурычларны җиренә җиткереп үти һәм зиратлар өстен дә һәрчак тәртиптә тота.

Мәчетебездә Ифтар, Корбан ашлары, Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.нең туган көнен олылап, Мәүлид мәҗлесләре үткәрәбез.

Мөгаллимебез Шәүкәт Фәйзуллин шәкертләргә гарәп графикасын, тәҗвид кагыйдәләрен өйрәтә. Мин, мөгаллимә буларак, тәҗвид белән Коръән укырга өйрәтәм.

Шушы уңышларым өчен мин Шенталы мәчетендә күп еллар буе барыбызга да дини белем бирүче остазыбыз Әнвәр ага Суфияновка бик рәхмәтлемен, – дип үз шатлыгы белән уртаклашты Нәсимә Исхак кызы.

Әңгәмәбез барышында мин аңа үземне кызыксындырган сорауларымны бирдем.

– Нәсимә апа, әйтегез әле, бүгенге көндә мөселман хатын-кызы нинди булырга тиеш?

– Аллаһы хатын-кызны үзенчә дөньяга китергән. Ул иренә тугры



тормыш иптәше, нәсел дәвамчылары – балаларына яраткан әни итеп яралтылган. Хатын-кызлар тәрбияле, әдәпле, инсафлы булырга тиеш. Урамда ачык киемнәрдән йөрергә ярамый. Чөнки бу - хәрам. Шушы сүзләр Изге Коръән китабында исбатланган.

– Әниләргә балаларны ничек тәрбияләргә? Бу мәсьәлә ирләргә дә кагыламы?

– Әйе шул. Раббыбыз ир белән хатын-кызны пар итеп җир йөзенә җибәргән. Шуның өчен бала тәрбияләп үстерү – әти-әнинең төп вазифасы. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә акча эшләү мәсьәләсе ирләр өчен беренче урында тора. Шулай да, ничек булса да, әтиләрнең, вакыт табып, хәләл җефетләренә балалар тәрбияләүдә булышулары изге гамәлләрдән санала. Җәмгыятебезгә яраклы, нәсел шәҗәрәсен лаеклы дәвам итүче, мәңгелеккә күчкән ата-аналар, әби-бабайлар рухына дога кылучы балалар калдыру фарыз гамәлләрдән санала.

– Бүгенге көндә гаилә кормыйча, бала тудырып үстермичә калган, бизнес белән шөгыльләнүче, карьера баскычыннан бик тиз өскә үрмәләүче хатын-кызларны очратырга мөмкин. Алар турында ни әйтер идегез?

– Тәкъдиребез, ашар-эчәр ризыкларыбыз, нинди һөнәр иясе булуыбыз ана карынында ук язылган. Шуның өчен бу турыда төгәл генә әйтеп тә булмый. Ә шулай да, гаилә кору, балалар тудырып-үстерү бурычы әллә кайчан билгеле. Ул гомер буе шулай килгән һәм алдагы тормышта да шулай дәвам итәчәк. Бөек шагыйребез Һади Такташ: "Хатын-кызның бөтен күрке, матурлыгы – Ана булуда", – дип тикмәгә генә язып калдырмас иде. Бу турыда бөтенләй онытырга ярамый. Ә бизнес дөньясына килгәндә, шатлыкка, бүгенге көндә менә дигән балалар тудырып-үстерүче хатын-кызларны да очратып була.

Менә шундый сөйләшү булып үтте остабикә, мөгаллимә Нәсимә ханым Сафина белән.

Рәхмәт, Нәсимә апа! Алдагы тормышта әҗер-саваплы эшегез һәрвакыт шулай матур дәвам итсен иде!

Дөрестән дә, Аллаһы ахирәт тормышына ирешкәнче гыйлем өстәргә, белем тупларга, шуларны киләчәк буынга тапшырып калдырырга кушкан бит. Безгә Нәсимә Исхак кызыннан үрнәк алырга кирәк.

# СПОРТ – удел смелых и сильных

***Борьба как вид спорта издревле является мощным средством воспитания таких качеств, как мужество, стойкость, сила, выносливость и упорство в достижении своих целей. Вот уже на протяжении 15 лет на базе школы «Яктылык» города Самары динамично развивается спортивная секция по борьбе. За этот период многие из учеников стали высококлассными спортсменами, мастерами спорта и чемпионами разных уровней. При этом школа «Яктылык» является предметом гордости всего татарского населения города Самары, где дети помимо хорошего образования также получают не менее достойное нравственное и физическое воспитание. Нам удалось встретиться с учителем физкультуры и тренером, мастером спорта по греко-римской борьбе Русланом Наилевичем Юсуповым и задать ему интересующие нас вопросы.***

***Фарид Шириязданов***




***– Не секрет, что во многих школах в отношении уроков по физическому воспитанию существует пренебрежительное отношение, и негласно считают его как бы второстепенным предметом. Что Вы скажете по этому поводу?***

– Очевидным является тот факт, что с развитием науки и техники физический труд все больше заменяется высокими технологиями, техникой и механизмами и на передний план выходит умственный труд. В итоге у многих развивается гиподинамия, из-за чего неминуемо возрастает количество людей с избыточным весом. А это, в свою очередь, влечет за собой массовое распространение сердечно сосудистых и других заболеваний. Более того, возрастает и количество детей с избыточным весом и ожирением. К сожалению, это явление уже обретает форму эпидемии. В данном случае никакие лекарства не смогут избавиться от беды. Не зря еще в древности говорили: «Движение – это жизнь!». В многозначительном словосочетании «физическая культура» содержится глубокая мысль. Здесь подразумевается не только культура тела и души, но и физиологическая активность, а это значит, жизнеспособность человека и его готовность к самореализации.

***– Кроме того, что являетесь преподавателем физкультуры, вы еще на профессиональном уровне ведете спортивную секцию по борьбе. Как педагог, что вы можете сказать о значении физкультуры и спорта, особенно в процессе воспитания подрастающего поколения?***

– Отчасти ответ на этот вопрос можно найти, глядя на живую природу. Там, как и у людей, дети всех живых существ растут, развиваясь в подвижных играх, среди которых преобладает борьба. Особенно красиво смотреть, как борются детеныши сурков и медведей, стоя на задних ногах. Более того, основоположник борьбы дзюдо Дзигоро Кано выработал комплекс приемов единоборства, изучая поведение и движения кошек и их диких сородичей, а также их психологию. При этом он ввел четыре правила: рациональное использование силы тела и духа; уметь поддаться, чтобы победить; умение использовать усилия соперника в свою пользу; глубокое понимание своей цели на пути достижения прогресса и совершенства. Несмотря на довольно жесткий характер этого вида единоборства, он утвердил следующие принципы: смелость, искренность, честность, скром-



ность, самоконтроль, верность в дружбе, уважение к окружающим. Даже пройдя через века, эти правила поведения не потеряли своей значимости и актуальности, и мы также стараемся воспитывать своих учеников в том же духе. Годы учебы в школе – это пора активного формирования ребенка как личности. Именно тогда он получает как умственное, так и физическое развитие. Поэтому от правильного физического воспитания зависит многое – его самооценка, устойчивость психики, физиологическая и умственная активность, а также состояние его здоровья в дальнейшей жизни в целом. У многих и достижение спортивного мастерства также происходит в школьные годы.




***– Занимаясь греко-римской борьбой, Вы также обучаете детей и приемам борьбы на поясах, а именно его разновидности – татарской национальной борьбы куряш. Какие у них имеются схожести и различия?***

– Эти виды борьбы оба имеют древнее происхождение, история которых тянется с доисторических времен. Известно, что греко-римская борьба пользовалась популярностью еще задолго до нашей эры, начиная с эпохи Античности. Она являлась одним из пяти видов единоборств во время Олимпийских игр. Пять колец, соединенных вместе, – поныне являются символом проводимых олимпиад на уровне пяти континентов. Ну а борьба на поясах являлась неотъемлемой частью оседло-кочевого, то есть экстремального образа жизни тюркских народов. Она занимала ключевое место на тренировках по боевым искусствам. Поскольку меняются эпохи и уже давно остались позади бои на лошадях, при этом борьба куряш сейчас стала лишь доброй традицией, лежащей в основе народных праздников. У греко-римской борьбы и борьбы на поясах имеются много схожих правил. В обоих из них запрещены подсечки, удары ногами и опасные приемы борьбы. В процессе схватки тут участвуют лишь части тела выше пояса.




***– Какова история борьбы на поясах, а именно ее разновидности, называемой куряш?***

– Многие традиции наших предков красивы, загадочны и имеют сакральный смысл. Именно они лежат в основе их жизненной стойкости, непобедимости и крепости их духа.

Борьба на поясах тогда была элементом боевого искусства. Во время боя воин, ухватившись за пояс, сбрасывал противника на землю. Ну а тренировки, проводимые тогда на земле, являлись



имитацией этого боевого приема. Со временем это стало лишь зрелищным видом спорта куряш, основным атрибутом и главным украшением больших сборов и многих праздников. О том, что борьба на поясах является одним из самых распространенных и древних видов спорта, говорят древние артефакты и исторические памятники искусства. Например, археологи находят наскальные рисунки с изображением борьбы на поясах в самых различных уголках Земли. Возле Багдада была найдена бронзовая статуэтка с изображением двух борцов на поясах, которой примерно шесть тысяч лет. Об этом также свидетельствуют памятники искусства кочевников, датируемых III и I веками до нашей эры. А также сцены борющейся пары, изображенные на бронзовых бляхах, найденных в Китае, и на серебряных сосудах, обнаруженных на берегах реки Обь в Тюменской области, где издавна жили тюрки. Известно, что борьба на поясах в Узбекистане также издревле была одним из видов боевого искусства и ее история насчитывает более 3500 лет. Состязания по ней там сейчас также устраиваются во время проведения больших церемоний и праздников.



***– В чем суть такой популярности этой борьбы?***

– Древние тюрки, предки современного татарского народа, были одним из древнейших народов Земли. Многие их традиции красивы, загадочны и имеют сакральный смысл. Вот они-то и лежат в основе их жизненной стойкости, непобедимости и крепости духа. Многие факты из их жизни, полны загадок и невероятных историй, поэтому они теперь нам кажутся сказками, далекими от правды. Но тот факт, что знания, которыми владели наши предки сейчас не доступны нашему сознанию – заставляют уважительно относиться к тем событиям, которые теперь называются легендами. Известно, что все слова также имеют сакральное значение и несут огромную смысловую нагрузку. Например, у древних тюрков слово «куряш» означало некую духовную связь между Средним и Верхним мирами, то есть между Небом и Землей. Если взять правила этой борьбы, там есть обязательное требование – перед броском борцу необходимо отрывать ноги соперника от земли. Это действие как бы означало лишить его от земного притяжения, то есть связи с энергетикой земли. В древности считалось, что высшие силы проявляют особую благосклонность к батырам, одержавшим победу во время проведения курултаев, джиенов, и они наделяют их особыми качествами. Поэтому их возвышали, возлагая на них особые надежды. В связи с этим ханы со своих плеч батырам дарили халаты, украшенные драгоценностями, и бесценных скакунов. Им отдавали в жены своих дочерей и объявляли их главнокомандующими войск. Если возникала в этом необходимость, то батыров даже избирали ханами, и, подымая на белой кошме, их носили по кругу, вблизи показывая народу. В то время, когда между различными ордами возникала угроза войны, они выставляли своих борцов на поединок. Зачастую после этого поединка стороны приходили к мировому соглашению.

***– Какие особенности имеются у борьбы на поясах?***

– У древних тюрков значительное место в жизни занимала систе-

ма символов и обрядов. Например, по отдельным элементам одежды можно было многое узнать о человеке. Даже по поясу, то есть по кушаку, можно было узнать: из какой местности его обладатель, какое место он занимает в обществе, в иерархии чинов и так далее. Поэтому у борцов наличие кушака было обязательным условием и он как бы являлся его визитной карточкой. При этом борцам было запрещено отпускать руки от кушака соперника, ставить подножки и наносить удары. Борьба на поясах отличается своей динамичностью и требует от спортсменов высокой физической подготовки, силы, ловкости и выносливости. Приемы в этой борьбе немногочисленны, однако каждый из них требует мастерства



и точности исполнения. Особое значение здесь имеет стратегия ведения борьбы, способность предвидеть действия соперника и умение мгновенно реагировать на них.

***– Имеет ли международное признание такой вид спорта, как борьба на поясах, и какое имеет распространение?***

– Этот вид борьбы распространен в таких странах, как Узбекистан, Казахстан, Киргизия, Туркменистан, Азербайджан, Турция, Иран и некоторых других. Куряш также входит в программу многих международных соревнований, включая Всемирные игры кочевников и Игры исламской солидарности.

Чемпионаты мира по поясной борьбе куряш ежегодно проходят в Республике Татарстан, где принимают участие спортсмены из 40 стран мира.

***– А в каких мероприятиях участвуют ученики школы «Яктылык»? Какие из них являются особо отличившимися и каких результатов они достигли?***



– Мы участвуем в различных соревнованиях по греко-римской борьбе городского, областных и республиканских уровней, на первенствах и чемпионатах федеральных округов, организуемых для юниоров и кадетов. Многие становится победителями и призерами.

***– В чем заключается значимость спорта сейчас, когда в обществе обесцениваются моральные устои, чувства солидарности и добрые отношения между людьми?***

– Любой человек, прошедший спортивную закалку, обычно достигает многого в жизни. Например, если взять великих мыслителей древности, как Сократ, Платон и Аристотель, – они были олимпийскими чемпионами. И такие знаменитости нашей современности, как М. Ш. Шаймиев, К. А. Титов, да и В. В. Путин – также являются мастерами спорта. Сейчас, когда наша страна с трудом избавляется от тех бед, которые навязали нам страны Запада, крайне важными является вопросы воспитания, особенно молодежи. А такие качества, как стойкость, мужество, моральная устойчивость, чувства солидарности и другие жизненно важные черты характера воспитываются именно в спортивной среде.

Но, к сожалению, системы физкультуры и спорта, которые были широко развернуты в стране раньше, теперь поставлены на коммерческую основу и стали недоступными для широкого круга людей. При этом радует то, что спортивная секция, сформированная в школе «Яктылык», сохранилась и поныне развивает свою деятельность, добиваясь значительных успехов. Здесь прежде всего надо отметить заслугу Халиуллова М. М., который в бытность работы председателем СОТНКА был инициатором создания секции спортивной борьбы в школе «Яктылык». Он и сейчас периодически оказывал нам определенную помощь. Хочется сказать слова благодарности и директору школы Р. Р. Газизову за понимание наших проблем и оказание содействия в сложные моменты. Сейчас нам тяжело и мы перебиваемся за счет небольшой финансовой поддержки областной федерации спорта. По мере своих сил и возможностей, стараемся не поддаваться трудностям, с надеждой на то, что вопросы развития спорта в будущем станут одной из первостепенных задач в нашей стране.



# КАНАФИЕВЫ.
## ИХ РОДИНА – ТЕПЛЫЙ СТАН

***История эта началась довольно давно. Еще в начале сентября 2017 года вместе с мужем своей младшей сестры, Юсуповым Чулпаном Габбасовичем, мы совершили поездку в село Теплый Стан, родину его мамы Вахитовой Камар Махмутовны. По итогам этого путешествия была написана пространная статья, которая через несколько лет была выложена в интернете.***

***Ильгизар Ахмедов,*** *г. Набережные Челны*

12 мая 2025 года получил сообщение от жительницы Санкт-Петербурга Магифиры Соловкиной:

*«Здравствуйте, Ильгизар! Моя аби – Халимова Саида, дочь муэдзина Канафиева Халима и его второй жены – Халимы из села Теплый Стан Самарской области. В 20-е годы семья была вынуждена бежать от голода и раскулачивания в Таджикистан (Халима и ее дети – Саида, Дания, Сария, Файзрахман). Прожили там до старости и смерти. В 50-е годы мама – Ляйли, мой брат, Дания опа и аби ездили в «Туплистан», о чем потом долго вспоминали. Сожалею, что мама не оставила никаких записок о предках, да и я не расспрашивала аби. Кое-что помню из ее рассказов. Очень хотела бы узнать, остались ли родственники в Теплом Стане. Читала Ваши воспоминания о поездке в эти края. Знаю, что Халим Канафиев был репрессирован и умер от туберкулеза в Архангельской области, но не нашла данных о нем в официальных списках репрессированных. Буду благодарна, если Вы пришлете мне ссылки на источники, в которых есть информация о моем прадеде. Мама рассказывала, что его трость хранилась в мечети. Кстати, Упомянутый Вами Губайдуллин Гарай (Гарай жизни) жил в Ташкенте. Детей у него не было. С благодарностью за Ваш труд – Соловкина (Алиева) Магифира (имя дала зур аби)».*

Буквально на следующий день удалось найти упоминание еще об одном сыне Канафиева Халима – Шакирзяне. Вопрос о поиске информации про своего прадеда Халимова Шакирзяна написал еще в августе 2019 года его правнук Абузяров Ренат:

*«Друзья, разыскиваю любую информацию о своем прадеде Халимове Шакирзяне, который родился и был в Елховке муллой (как рассказывают) в 1930 году. В том же году был репрессирован.*

*Буду благодарен за любые крупицы информации и советы к кому еще можно обратиться. Пишите в личку».*

В моей библиотечке имелась книга «Течение времени», написанная жителем селения Теплый Стан Абдуллой Насыровым в 2005 году. В поисках сведений о Канафиевых я перелистал это издание.

В этой книге на странице 32 нашлось упоминание о муэдзине Халиме:

*«Сабакаево было отдельной деревней, но и она оставалась отдельной махаллей. Жизнь вносит свои коррективы. В 1893 году возник пожар в доме муадзина Халима. Много домов погорели, пожар достиг каменной мечети. В то же время сгорела и Сабакаевская мечеть».*

На странице 316 в перечне «Видные личности мечети села – муллы» при «Новой деревне (Янавыл) – Сабакаевская мечеть» приводятся сведения о следующих людях духовного звания:

4. Канафеев Халим, муадзин в 1911–1919 годах.

5. Канафеев Мухаматвали в 1911–1919 годах (умер от голода в 1921 году).

6. Халимов Шакирзян – мулла, сын муадзина Халима.

Был арестован, сидел в тюрьме г. Архангельска, заболев туберкулезом умер.

Приходилось встречать в иных источниках упоминание еще об одном священнослужителе Сабакаевской мечети – Хуснулла, сын муэдзина Мухамметвали (Ханафиев). Созвучие фамилий Канафиев – Ханафиев и принадлежность к числу священнослужителей подталкивает к мысли об их принадлежности к одному семейству.

Сведения о Халимове Шакирзяне нашлись в списках репрессированных:

*«Халимов Шакирзян*

*Родился в 1887 г., с. Елховка; татарин; б/п; крестьянин.*

*Арестован 4 февраля 1930 г.*

*Приговорен: тройка при ПП ОГПУ по Средне-Волжскому краю 25 февраля 1930 г., обв.: по ст. 58–10.*

*Приговор: к 8 годам заключения в концлагере Реабилитирован 11 декабря 1989 г. Куйбышевской облпрокуратурой.*

Источник: Книга памяти Самарской обл.».

*«Халимов Шакирзян (1892 –?) – уроженец с. Теплый Стан, сын муэдзина Халима, мулла т.н. Сабакаевской мечети в 1919–1930 гг. В 1920 е гг. был лишен избирательных прав. В 1930 г. был арестован как противник колхозного строительства. В момент ареста имел скромное хозяйство – 6,35 десятины земли, скота не было. Приговор: 8 лет концлагеря с конфискацией имущества. Срок отбывал в г. Архангельске, где скончался от туберкулеза».*

Вот, пожалуй, и все, что удалось узнать о Канафиеве Халиме и его сыне Шакирзяне.

В конце мая этого года получил письмо от Магифиры Соловкиной, в котором она собрала все известные ей сведения о Канафиевых-Халимовых. Процитирую выборочно.

*«Канафиев Халим и его вторая жена – Халима приходятся мне прадедом и прабабушкой. Об их происхождении ничего не знаю, вероятнее всего – не помню. Аби говорила, что Халим бабай был муллой в мечети села Теплый Стан («Туплистан») Елховского района Самарской губернии, где они и жили. Дат рождения и смерти, к сожалению, не знаю. Места захоронения – тоже. Первая жена умерла, оставив ему сына – Шакирзяна.*

*О своем отце моя аби почти ничего не рассказывала. Говорила, что он был добрым, баловал их, чем мог – по праздникам покупал сладости, давал мелкие деньги. От чего умер – не говорила. Произошло это в 20-е годы.*

*Халима родилась в 1884 году. Ее выдали замуж 15-летней девочкой. Она родила 10 детей, большая часть которых умерла в раннем детстве от болезней. Одну девочку в возрасте 4–5 лет застрелили «солдаты», которые пришли в поисках излишек продуктов. Малышка играла под столом, накрытым длинной скатертью. Когда она зашевелилась – в нее выстрелили. (Предполагаю, что искали не продукты – возможно, кого-то из людей. Иначе зачем было стрелять?)*

